*Ий, мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!*
*(Коръәни-Кәрим, 3:103.)*

# ДИН вә МӘГЫЙШӘТ

6+ ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ • №3 (224) МАРТ 2014 / ҖӨМӘДИӘЛӘҮВӘЛ 1435

## БҮГЕНГЕ САНДА:

КАЗАНЬ
СЕВЕРНАЯ СТОЛИЦА МУСУЛЬМАНСКОГО МИРА

### "КАЗАН – МӨСЕЛМАН ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТӨНЬЯК БАШКАЛАСЫ

**"Хузур" нәшрият йорты әнә шундый товар билгесен теркәтү өчен заявка бирде**

2 нче бит



### МӘЧЕТЛӘРНЕ КЕЛӘМНӘР ТҮГЕЛ, МӨСЕЛМАННАР БИЗӘРГӘ ТИЕШ

3 нче бит




### ИЛ ЯШӘВЕ – МОҢ БЕЛӘН

8 нче бит

## ИМИНЛЕК СЕЗГӘ!



Әссәләәмү галәйкүм үә рахмәтүллаһи вә бәракәәтүһ!

Иминлек, Аллаһның рәхмәте һәм сәламе сезгә! Шушы сүзләр белән Мөхәммәд пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вәссәлам) мөселманнарга бер-берсенә сәлам җиткерергә куша. Габдулла ибне Сәлам (радыйаллаһу ганһү) тапшырган хәдистә Аллаһ Рәсүленең мондый сүзләре җиткерелә: **"Ий кешеләр, башкаларга сәлам җиткерегез, аларны ризык белән туендырыгыз, башкалар йоклаганда төннәрен намаз укыгыз һәм сез бик имин Җәннәткә керерсез!"** (әт-Тирмизи, 1855).


Шуңа игътибар итегез, Мөхәммәд пәйгамбәр (салләллаһу галәйһи вәссәлам) шундый гади генә бер эшне – бер-береңә сәлам җиткерүне төнге намаз белән беррәттән куйган. Әлбәттә, бу аларның бер-берсен алыштыруын аңлатмый, алай дип уйлау – ялгышу, ә без ялгыш фикер йөртүләрдән читтә торырга тиеш. Моның мәгънәсе шунда: сәлам җиткерүнең әһәмияте төнлә намаз уку кебек үк югары. Әмма төнлә намаз уку һәркемнең үз ихтыярында булса, мөселман кардәшеңә сәлам җиткерү – синең мөселманнарның берләшүенә керткән өлешең.

Ислам – иҗтимагый дин, бикләнеп утыру аңа хас түгел. Аллаһы Тәгалә Коръәндә болай ди: **"Игелек итүдә, яман эш кылудан саклануда бер-берегезгә ярдәмләшегез"** *("Маидә (Табын)" сүрәсе, 2 нче аять).* Ярдәм итешегез! Нәкъ менә яхшы, игелекле эшләр кылуда ярдәм итешегез! Исламның таралуына, динне өйрәнүдә, кыен вакытларда башкаларга ярдәм ит. Ярдәм ит һәм шуның белән Аллаһка якынай һәм башкаларны да Аллаһка якынайт. Әнәс (радыйаллаһу ганһү) тапшырган хәдис исә Пәйгамбәрнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) шундый сүзләрен җиткерә: **"Үзенә теләгәнне башкаларга да теләми торып, сезнең арагыздан берегез дә иманлы була алмас"** (әл-Бохари; Мөслим).

Әйе, безгә төрлечә ялган кыйммәтләр тагарга тырышалар: "Һәркем – үзе өчен генә һәм анда минем эшем юк". Тарих андый таркаулыкның нинди нәтиҗәләргә китерүе турында күп мисаллар белә. Хәзерге вакытта да безгә тәкәбберлек, мин-минлек, башкаларны кабул итмәү һәм аңламау, үзеңнең ялгыш фикереңне башкаларга тагу нәтиҗәсе булган үзәк өзгеч вакыйгалар турында ишетергә туры килә. Аллаһы Тәгалә үзара мәсьәләләрне чишкән вакытта кан коешу дәрәҗәсенә җиткермәскә куша: **"... низаглашуда Аллаһтан куркыгыз вә арагызны төзәтегез"** *("Әнфал (Табыш малы)" сүрәсе, 1 нче аять).*

"Сахих Мөслим"дә (№ 2626) Әбу Зәрр әл-Гифари тапшырган хәдистә Пәйгамбәрнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) шундый

***АХЫРЫ 2 НЧЕ БИТТӘ***



**МИН НИ ӨЧЕН "ДУМ РТ ХАДЖ"НЫ САЙЛЫЙМ?**

9 нчы бит



**НИКАХ ӘДӘБЕ**

11 нче бит

Система добровольной сертификации продукции и услуг
Халяль حلال Halal
на соответствие канонам ислама - система халяль

**"ИТЕГЕЗ ХӘЛӘЛМЕ"?**

15 нче бит

**ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘННӘН АЯТЬЛӘР БАР, АНЫ ТИЕШСЕЗ УРЫНГА КУЛЛАНУДАН САКЛАНЫГЫЗ!**

## ИМИНЛЕК СЕЗГӘ!

*АХЫРЫ . БАШЫ 1 НЧЕ БИТТӘ*

сүзләре җиткерелә: **“Игелекле эшләрнең берсенә дә сөйми карама, ә мөселман кардәшеңне очратканда аңа елмай (йөзең шат, якты булсын)”.**

Ә без нишлибез? Безгә яхшылык теләп, үзебезгә һәм бар ислам өммәтенә пычрак ташлаган ниндидер бер начар гамәлебезне, сыйфатыбызны күрсәткән кешегә елмаеп карамау гына түгел, аңа ничек тә булса зәһәррәк сүз белән җавап бирергә тырышабыз. Шуның белән арабыздагы упкынны тагын да тирәнәйтәбез. Аннан соң үзебез үк шул упкынга очабыз.

Әгәр бер гаилә эчендә дә кешеләр бер-берсен аңлый алмый икән, таныш булмаган кешеләргә мөнәсәбәт турында әйтеп тә торасы юк. Без тирәбездәге кешеләргә карата саңгыраубыз. Без хатыныбыз ни әйтергә теләгәнен дә аңлый алмыйбыз. Ә балаларыбызны гомумән күрмәмешкә салырга тырышабыз. Ә бит алар алдындагы җаваплылык безгә йөкләнгән. Аллаһы Тәгалә әйтә: **“Раббың бары тик үзенә генә гыйбадәт кылуыгызны, ата-анагызга да игелекле булуыгызны катгый рәвештә боерды. Аларның берсе яки икесе дә сезнең янда картайса, сак булыгыз, аларга: уф *(туйдым сездән)*, димәгез; аларны битәрләмәгез; икесенә дә яхшы мөгамәләдә булыгыз, алар белән йомшак сөйләшегез. Миһербан һәм түбәнчелек белән алар алдында *(күңел)* канатларыңны җәй дә әйт: “Раббым, сабый чагымнан алып, алар мине ничек сөеп үстергән булса, Син дә аларга шулай мәрхәмәтле бул”, – дип дога кыл”** *(“Исра (Төнге йөрү, Ягъкуб угыллары)” сүрәсе, 23-24 нче аятьләр).* Ә без шул рәвешчә гамәл кылабызмы соң?

Без хәзер җәмгыять ачыграк, безнең заманда төрле элемтә чаралары – телефон, интернет, социаль челтәрләр куп, дибез. Алайса ни өчен соң без якыннарыбыз белән еллар буе очрашмыйбыз? Вакыты-вакыты белән генә очрашып алабыз, анысы да зиратта, кайсыдыр бер кардәшебезне җирләгәндә. Аны да без бары тик бер тапкыр гына, кечкенә вакытта гына күргән булабыз, ә аннары үсеп җитәбез, аның белән ачуланышабыз һәм аралашудан туктыйбыз. Җыелышабыз. Җирлибез. Аннан таралышабыз. Икенче бер очракка – башка берәүне җирләгәнгә чаклы. Ә бит ул икенче очрашуның сәбәбе – аның үз җеназасы булмавына беркем дә гарантия бирә алмый.

Бу – мөселманнарча түгел. Без, мөэмин-мөселманнар, бердәм булырга тиеш. Гыйбадәт кылуда, фикерләрдә, гамәлләрдә. Аллаһы Тәгалә мөселманнарга һәр җомгада мәчеткә җомга намазына җыелырга кушкан. Габдулла ибне Гомәрдән Мөхәммәд пәйгамбәрнең (салләллаһу галәйһи вәссәлам) шундый сүзләре тапшырыла: **“Җәмәгатьтә укылган намазның (савабы) аерым гына укылган намаз савабыннан 27 тапкыр артык”** (әл-Бохари, № 645). Изге рамазан ае буена без ифтарларга җыелабыз. Мәүлид аенда да җыелып соңгы Пәйгамбәргә (салләллаһу галәйһи вәссәлам) салават әйтәбез. Мөселманнарның олы бәйрәме – Ураза һәм Корбан гаетләрендә мәҗлескә туганнарыбызны җыябыз. Ә мөселманнарга мәрхүмнәрнең “өчесе”н, “җидесе”н, “кырыгы”н, “елы”н үткәрүне, Коръән укуны бидгать дип атап, аны тыю – гомумән, ахмаклык.

Мөселман җәмгыяте менә шулай яши. Бергәләп һәм берләшеп. Бербөтен булып. Берсе икенчесе өчен җавап бирә. Мәрхүмнең бурычларын аның туганнары түли. Хәлле кешеләр мохтаҗларга ярдәм итә. Фарыз намазларны укыганда да мөселманнар иңгә-иң баса. Шайтан үзе дә үтеп керә алмаслык тыгыз рәтләр белән. Мөселманнар тыныч тормыш белән гомер итә. Үзара үзләре генә түгел, ә бүтән дин вәкилләре белән дә. Менә шундый җәмәгатьне таркатып, алар арасында фетнә таратып булмый. Чөнки таркалу – явызлык, тәкәбберлек һәм мин-минлек хөкем сөргән җирдә була. Ә мөселман өммәте бары тик тынычлык, Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкатен, Аның рәхмәтен алырга тели.

Әссәләәмү галәйкүм вә рахмәтүЛлаһи үә бәракәәтүһ!

**Татарстан Республикасы мөфтие**
**Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**

## ГАИЛӘҢНЕ САКЛЫЙМ ДИСӘҢ...

Башкаланың Гаилә мәчетендә һәр атнаның сишәмбе көннәрендә ахшам намазыннан соң гаилә дәресләре уткәрелә башлады. Дәресне Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин алып бара. Аның беренчесе гаилә тормышының этаплары каралган иде. Икенче дәресне хәзрәт гаиләдә үзара мөнәсәбәтләрне коруга, гаиләне саклап калуга багышлады. “Сез ни өчен гаилә кордыгыз?”- дигән сорауга хәзерге заманда җаваплар күптөрле: кемдер нәселне дәвам итү өчен; кемдер (башлыча, мөселманнар) гөнаһка кермәс өчен; матди проблемаларны чишү өчен; рухый терәк эзләп; “гаиләле” дигән социаль статуска ия булу өчен гаилә кора. Коръәни-Кәримдә Аллаһы Тәгалә Үзе гаилә корырга кушкан һәм без Аның әмерен үтәргә тиеш. Ә инде гаиләбез бәхетле, бәрәкәтле булсын өчен Аллаһының куйган шартларын үтибезме? Гел бәхеттә-бәрәкәттә генә яшәргә дип төзелгән гаиләне нәрсә җимерә? Аны ничек сакларга? Дәресләрдә әнә шул сорауларга җавап табарга була.



# КИЛЕШҮГӘ КУЛ КУЕЛДЫ

**Татарстан мөфтие резиденциясендә Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте белән Россия Федераль миграция хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куелды.**

Килешүне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Россия Федераль миграция хезмәтенеңТатарстан буенча идарәсе җитәкчесе Сергей Чепуштанов имзалады. Чарада Россия ФМХ үзәк аппараты вәкилләре Татьяна Пимок и Вадим Морокин, ФМХнең Татарстан буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары Рөстәм Вәлиуллов һәм ТҖ МДН үзәк аппараты җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев катнашты.

Имзаланган килешү ислам динен тотучы мигрантларга ярдәм күрсәтү буенча уртак эшчәнлекне; ТҖ МДНә миграция өлкәсендә консультация, методик һәм гамәли ярдәм күрсәтүне күздә тота.

Чарада ТҖ МДН вәкилләренең мигрантларның адаптациясенә ярдәм итә торган программаларны тормышка ашыручы белем бирү үзәге эшчәнлегендә катнашуы да каралды. Шулай ук Россиядә яшәүче халыкларның мәдәнияте, традицияләре белән таныштыру максатыннан Диния нәзарәтенең мәгълүмати ресурсларын төрле телләрдә файдалану мәсьәләсе дә күтәрелде.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Диния нәзарәтенең Федераль миграция хезмәтенә ярдәм итәргә әзер булуын белдерде һәм нәзарәтнең дәгъвәт бүлегенең мигрантларны адаптацияләүдәге эшчәнлеге турында житкерде. Шулай ук мөфти хәзрәт ТҖ МДНең интернет-проектлары, “Хузур” нәшрият йортының нәширлек эшчәнлеге турында сөйләде. Камил хәзрәт илгә килүче мөселманнарга РФ миграция законнарын аңлатуда Россия Федераль миграция хезмәтенә мәгълүмати ярдәм күрсәтәчәкләренә ышандырды.

Чарада шулай ук мигрантларның социаль-мәдәни адаптациясен тизләтүгә ярдәм итә торган уртак чаралар үздыру турында да фикер алыштылар.

# “КАЗАН - МӨСЕЛМАН ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТӨНЬЯК БАШКАЛАСЫ”

**Казан, бөтендөнья мөселманнарының мәдәният үзәге буларак, исламны таратуда һәм саклауда һәрвакыт зур роль уйнады. Ислам дине фикере, фәлсәфәсенең үсеше тарихы, китап бастыру эше, мөселман мәгарифе нәкъ менә Казан белән бәйле. Бөтендөнья ислам тарихы казанышы булган күренекле тәгълиматчылар да Казанда үсеп чыкты.**

Казан - бүгенге көндә ислам кыйммәтләрен, шулар арасында конфессиара килешеп яшәү үрнәген тормышка ашыручы төбәк башкаласы да. Шуның өстенә нәкъ менә хәзерге татарстанлыларның әби-бабалары X гасырда Россиядә беренчеләрдән булып рәсми төстә исламны кабул иткәннәр, шуннан соң ислам бөтен Россия территориясендә киң таралыш алган. Болар хаклы рәвештә Казанны мөселманнарның төньяк башкаласы дип атарга мөмкинлек бирә.

Үзенең эшчәнлеген дөнья һәм татар ислам тәгълиматчылары мирасын саклауга, популярлаштыруга юнәлдергән “Хузур” нәшрият йорты “Казан – мөселман дөньясының төньяк башкаласы” дигән товар билгесен теркәтү өчен Роспатентка заявка бирде. Бу товар билгесе “Хузур” тормышка ашырырга планлаштырган барлык басма, аудио-видеопродукция, һәм интернет-проектларны берләштерәчәк.

“Хузур” нәшрият йорты директоры Ришат Хәмидуллин әйтүенчә, заявка Яңа елга кадәр үк бирелгән, нәтиҗәсе күзгә билгеле булачак.”Товар билгесенең дизайнын, безнең теләкләрне искә алып, “Хузур”ның үз дизайнерлары иҗат итте. Ул республиканың символы булган Сөембикә манарасыннан һәм ислам символы – лалә чәчәгеннән гыйбарәт. Идеясе һәркемгә аңлаешлы булсын өчен шушы символикага тукталдык”,- ди Ришат әфәнде.

# ИЛДАР БАЯЗИТОВ – 2013 НЧЕ ЕЛ ХӘЙРИЯЧЕСЕ

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында ел хәйриячеләренә дипломнар тапшыру тантанасы булды. Хәйриячеләргә бүләкләрне Татарстан Президенты, Хәйриячелек эшчәнлеге мәсьәләләре буенча республика советы рәисе Рөстәм Миңнеханов тапшырды. "2013 нче ел хәйриячесе" исеменә Татарстан мөфтие урынбасары, Ярдәм мәчете имам-хатыйбы Илдар хәзрәт Баязитов лаек дип табылды.

Илдар хәзрәт Баязитов - Россиядә һәм БДБ илләрендә тиңе булмаган Ярдәм мәчетенең имам-хатыйбы. Бу комплекста гыйбадәт кылу залы, чит җирләрдән килүчеләр өчен тулай торак, ашханә, компьютерлар классы, китапханә, мини-басмаханә бар. Бүлмәләрдә инвалидларга тиешле барлык шартлар тудырылган, алар пандуслар белән җиһазландырылган.



# МӘЧЕТЛӘРНЕ КЕЛӘМНӘР ТҮГЕЛ, МӨСЕЛМАННАР БИЗӘРГӘ ТИЕШ

**Безнең бүлек хезмәткәрләре һәрвакыт юлда. Соңгы вакытларда иман кичәләрен авылларның мәдәният йортында уздыра башладык. Моның сере гади: мәчеттә уздырган кичәгә бары тик мәчеткә йөрүчеләр генә килә, ә инде мәдәният йортына чакырсак, кызыгып, дин тотмаучылар да килергә мөмкин. Вәгазьләрдән тыш мөнәҗәтләр дә башкарабыз, соңыннан викториналар уздырабыз.**

Гади генә сораулар бирәбез без анда, мәсәлән: “Исламның баганалары нидән гыйбарәт?”, “Пәйгамбәребез галәйһиссәлам нинди шәһәрдә туган?” һ.б. Дөрес җавап биргән кешегә кечкенә генә булса да бүләк тапшырабыз. Монда да дәгъвәт бар. Динне белмәүче, дөрес җавапны белмәүче җавап бирүчегә карап соклана. Аның күңелендә, мин дә белә алам бит инде бу нәрсәләрне, миңа да өйрәнергә кирәк, дигән уй туып, мәчеткә дә йөри башлар, иншә Аллаһ.

> ***Бүгенге вазгыять шундый: мәчетләр җитәрлек дип әйтергә була, ләкин кайбер авылларда алар буш. Мәчетләрне матур келәмнәр, матур шәмаилләр бизәргә тиеш түгел бит, ә дин кардәшләребез, мөселманнар бизәргә тиеш.***

Шундый иман кичәсен Кукмара мәдәният йортында да уздырган идек, Кукмара мәдрәсәсе директоры шалтырата: “Кичәдән соң бер егетебез мәчеткә йөри башлады”, - ди. Мондый хәбәрләр безне бик сөендерә. Мәдәният йортына 200 кеше җыелып, шуларның берсе генә иманның әһәмиятен аңлап, мәчеткә килсә, бу да безнең өчен нәтиҗә. Чөнки хәдисләрдә әйтелгәнчә, бер генә кешене дингә китерсәк тә, ул бик зур әҗер.

Кая чакырсалар, шунда барырга тырышабыз. Узган елның маеннан кайсы районнарда гына булмадык: Биектау, Кукмара, Әгерҗе, Арча, Әтнә, Яшел Үзән, Мамадыш, Чистай... Һәрвакыт сәфәрдә без. Аллаһы Тәгалә шундый вазыйфаны йөкләгән икән, без аны җиренә җиткереп үтәргә тырышырга тиеш. Кыямәт көнендә Ул: “Сиңа белем бирелде, ул белемнән ничек файдаландың?”, “Яшьлек бирелде, аннан ничек файдаландың?”- дип һәммәбездән дә сораячак бит. Без бу эшләрне Аллаһының рәхмәтенә, ризалыгына ирешер өчен башкарабыз. Мәчетләргә кешеләрнең күбрәк килүен телибез. Бүгенге вазгыять шундый: мәчетләр җитәрлек дип әйтергә була, ләкин кайбер авылларда алар буш. Мәчетләрне матур келәмнәр, матур шәмаилләр бизәргә тиеш түгел бит, ә дин кардәшләребез, мөселманнар бизәргә тиеш. Гали радыйаллаһу ганһүнең, шундый заман килер - кешеләрнең күңелләрендә тәкъвалык булмас, мәчетләр буш торыр, дигән сүзләре бар.

Кайбер районнарның мәдәният йортларына хәтта 500 кеше җыелган вакытлар булды, әлхәмдүлилләһ. Вәгазь укыганда, мөнәҗәтләр башкарганда кешеләрнең күзләренә карыйсың: сине шундый игътибар белән тыңлыйлар, аларның чынлап та рухый ризыкка бик мохтаҗ икәнлеген күрәсең. Кичәләрдә еш кына район хакимияте башлыгы урынбасарлары, хакимият вәкилләре дә катнаша, бу да безне бик сөендерә. Алар һәрвакыт халык исеменнән безгә рәхмәт сүзләрен җиткерәләр. Мәдәният йортыннан чыгып барганда, яныбызга килеп, аерым-аерым рәхмәт әйтеп китүчеләр дә бар.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин исеменә бик ерак бер авылдан – Әгерҗе районының Ямурза авылыннан хат килде. Анда авылда мәчеткә йөрүче кешеләрнең саны артуы, бер ел эчендә егерме кешенең намазга басуы турында тәфсилләп язылган иде. Без вәгазьләргә бик мохтаҗ, берәр хәзрәтне җибәрә алмассыз микән, дип язганнар иде ямурзалылар. Мөфти хәзрәт бу хатны миңа тапшырды. Һәм без - Руслан хәзрәт Фәрхетдинов (ул элек дәгъвәт бүлегендә эшли иде, хәзер Болгардагы Ак мәчетнең имам-хатыйбы) һәм Руслан хәзрәт Ясәвиев, Ямурза авылына барып, вәгазь кичәсе үткәрдек. Рәхмәтләрен әйткәннән соң, алар һәр якшәмбе көнне бер хәзрәт килсә иде, дигән үтенечләрен дә җиткерделәр. Бу эшне Түбән Кама мөхтәсибе Йосыф хәзрәт Дәүләтшин үз өстенә алды, я үзе барып, я ярдәмчесен җибәреп анда вәгазь сөйләделәр. Ямурзага беренче тапкыр килүебездә безгә төзелә башлаган мәдрәсәне күрсәткәннәр иде. Күптән түгел ул мәдрәсә ачылды, бәйрәмгә без дә чакырулы идек, клубта бик матур мәҗлес ясадылар. Теге якшәмбе вәгазьләре өчен халыкның рәхмәт сүзләрен ишетү безгә бик рәхәт булды. Мәчетнең өлкән яшьтәге хәзрәте белән кулга-кул тынышып эшләсен дип, мәдрәсәгә бер яшь хәзрәтне билгеләдек.

Соңгы вакытта “Зәкят” хәйрия фонды белән бергәләп балалар өчен викториналар уздырабыз. Күбесенчә яшь имамнарны үзебез эшкә җибәргән авылларга барабыз. Мәчетләргә балаларны җәлеп итүдә аларга да бер ярдәм булыр, дибез. “Зәкят” хәйрия фонды генераль директоры Илнур Вәлиев та динебез өчен бик борчыла торган кеше. Яшьләрне дингә тартуда кулдан килгәнчә ярдәм итә.



Викториналар үткәрү турында аның белән утырып сөйләштек тә, фонд бүләкләр әзерләүне үз өстенә алды.

Беренче викторинабыз Арчаның Апаз һәм Урта Курса авылларында узды. Алдан ук мөхтәсиб, җирле үзидарә җитәкчесе, мәктәп директоры белән сөйләшеп куйган идек. Мәчеткә йөрмәүче балалар да катнашсын, сорауларга җавапны белмәсәләр дә күреп, ишетеп утырсыннар, дидек. Аллаһының рәхмәте булсын, бөтен балаларны шунда җыйганнар – Апазда 125 кеше катнашты. Вәгазь укыдык, Ильяс Халиков белән РИУ шәкерте Сәет Дауд мөнәҗәтләр көйләде. Балалар шундый матур итеп җаваплар бирделәр, урыннарны билгеләп, бүләкләр тапшырдык, барысына да шоколадлар тараттык. Монысы - балаларны мәчеткә китерү өчен үзенә күрә бер стимул инде.

Халык арасына чыгарга кирәк, халык өметсез түгел. Әмма коры вәгазь генә җитми ул, шуңа күрә төрле ысуллар кулланабыз. Кайберәүләргә вәгазь үтеп кермәскә мөмкин, ә мөнәҗәт аша үтә. Алга таба без Чаллыга, Бөгелмәгә барырга җыенабыз, май ахырында, һәрбер районнан ике-өч баланы чакырып, Болгарда, Ак мәчеттә республика викторинасы үткәрергә ниятлибез.

Безнең әле төрмәләрдә дә бик зур эшләр башкарыла. Татарстанда тугыз төрмә бар. Зөя утравындагы 5 нче колониягә аерым тукталасым килә. Без анда тиздән мәчеткә йөрүче тоткыннар арасында ислам гыйлемнәре буенча бәйге уздырырга җыенабыз. Узган ел әлеге төрмәдә үткәрелгән бәйгедән шаккатып кайткан идем. Тоткыннар гарәп телен мәдрәсәнең икенче курсында укучы шәкерт кебек беләләр. Шунда әзерләнеп бит ул! Хәзерге вакытта мәчеткә йөздән артык тоткын йөри, мәчетләре элек бер генә катлы иде, хәзер ике катлы итеп төзекләндереп яталар. Казан төрмәләре дә безнең игътибардан читтә түгел, алар өчен дәгъвәт бүлегенең ике хезмәткәре җаваплы, Кама аръягы төбәге өчен - бер кеше. Тоткыннар арасыннан берәрсен без имам итеп билгеләп куябыз. Башта белемен тикшереп, аңа шәһадәтнамә бирәбез. Бу нәрсәгә бик игътибарлы булырга кирәк. Әгәр дә ул мөфтият тарафыннан билгеләнмәсә, башка караштa булган, белемсез, тәҗрибәсез кеше имам булып, башкаларга да тискәре йогынты ясарга мөмкин. Төрмәләрдә җомга вәгазьләре сөйлибез, лекцияләр укыйбыз, аларга китаплар илтәбез. Ураза һәм Корбан гаетләрендә мәчеткә йөрүчеләр өчен мәҗлесләр үткәрәбез.

Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре, колония хезмәткәрләре өчен дә лекцияләр укыйбыз. Ислам, мөселманнар, аларның башка диннәргә мөнәсәбәте турында мәгълүмат бирсәгез иде, дип алар үзләре безне чакыралар. Ислам гакыйдәсен, ислам артына яшеренгән төрле агымнарны өйрәнү өчен Казанга башка төбәкләрдән дә килгәннәр иде. Без аларга да лекция укыдык, Диния нәзарәтенең төрмәләрдә эшләү тәҗрибәсе белән дә уртаклаштык. Алар өчен бу бик кызыклы булды.

Без мигрантлар белән дә эшлибез. Күптән түгел дәгъвәт бүлегенә яңа хезмәткәр алдык. Гали хәзрәт Ибодов – таҗик милләтеннән, бик белемле, укымышлы хәзрәт (аны мөфти Камил хәзрәт үзе тәкъдим итте). Һәр атнаның сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә ул Вьетнам базарындагы гыйбадәт бүлмәсендә базарда эшләүче мигрантларны җыеп, аларга хәнәфи мәзһәбе буенча вәгазь укый, безнең гореф-гадәтләребез турында сөйли, сорауларга җаваплар бирә, проблемаларын хәл итәргә тырыша. Киләчәктә мигрантларны җыеп, үзебез дә лекцияләр укый башларга ниятләп торабыз. Бу да бик зур һәм бик кирәкле эш.

Пәйгамбәребез, үз халкына хезмәт кылган кеше шул халыкның дәрәҗәле кешесе, дигән. Һәр мөселман кулдан килгәнчә халыкка хезмәт итәргә тиеш. Чын күңелдән хезмәт кылсак, иншә Алла, нәтиҗәсе дә булмый калмас.

**Нияз хәзрәт САБИРОВ,**
**Татарстан мөфтие урынбасары,**
**Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе**

# АТА-АНАГА МӘХӘББӘТ

**Ата-анага мәхәббәтне гыйбадәтнең бер төре дияргә була. Аллаһы Тәгалә аларны синең бу дөньяга килүеңнең сәбәбе итә, алар кулы белән сине үстерә һәм тәрбияли. Ата-анаң картаеп, файда түгел, ә киресенчә, кыенлыклар китерә башлагач, аларга карата мәхәббәт, мәрхәмәт күрсәтсәң, бу синең Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәтеңне һәм хөрмәтеңне күрсәтүең булачак. Аллаһы Тәгалә болай дигән: “Аллаһ хөкем итте вә әмер бирде, фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга “уф” та димә вә каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә, бәлки аларга, һәрвакыт йомшак вә мөлаем сүзләр сөйлә!” (“Бәни Исраил” сүрәсе, 23 нче аять).**



Бер шәһәрдә әтисе белән улы яшәгән. Әниләре булмаганга күрә, улын әтисе үзе генә тәрбияләгән. Дөресен генә әйткәндә, малай бик үк тәртипле булмаган. Шуңа күрә әтисе аңа еш кына: “Синнән кеше чыкмаячак”, - дип әйтә торган булган. Әлбәттә, бу сүзләр малайның йөрәгенә тия, мәктәпне тәмамлагач, ул өйдән чыгып китә. Шәһәргә килеп, эшкә урнаша, хәзерлек курсларына бара, университетка укырга керә. Ә колагында һәрвакыт әтисенең сүзләре яңгырап тора: “Синнән кеше чыкмаячак”. Еллар уза, ул укуын дәвам итә. Уңышлы гына университетны тәмамлап, туган шәһәренә кайта. Эшкә урнаша, эшендә уңышларга ирешә, шәһәр башлыгы булып эшли башлый. Аның әтисе белән еллар дәвамында аралашмаганын аңлагансыңдыр инде. Ниһаять, ул әтисен мэриягә кабул итү бүлмәсенә чакырта. Карт бүлмәгә керә һәм чиксез гаҗәпләнә - шәһәр башлыгы урынында аның улы утыра. Улы тынлыкны беренче булып боза: “Син миннән кеше чыкмаячак, дия идең. Күрәсеңме, минем нинди дәрәҗәгә ирешкәнемне? Үзем югары уку йортына укырга керә алдым, аны кызыл диплом белән тәмамладым, туган шәһәремә кайттым һәм барысына да үзем ирештем. Күрәсеңме, мин кем булдым? Ә син нәрсә дип әйтә идең?..” Әтисе чал башын чайкап: “Улым, улым! Мин бит син университетка керә, аны тәмамлый алмаячаксың, шәһәр башлыгы була алмаячаксың, дип әйтми идем. Мин, кеше була алмаячаксың, дия идем.. Кеше булсаң, син үз әтиең белән болай эшләмәс идең!”- ди.

Увәйс турындагы хикәяне ишеткәнең бармы икән? Ул Пәйгамбәребез (с.г.в.) заманында яшәгән. Авыру әнисен калдырып китә алмаганлыктан, аңа Пәйгамбәребез (с.г.в.) белән очрашу насыйп булмый. Аллаһы Тәгалә аның дәрәҗәсен күтәрә, чөнки ул чынлыкта Пәйгамбәрне дә (с.г.в.), әнисен дә бик ярата. Пәйгамбәребез (с.г.в.) аның догаларының кабул булуын әйткән һәм хәтта бүләк итеп аңа үзенең күлмәген тапшырырга кушкан. Мәхәббәт ул - бөек хис! Усайр бин Амрның болай диюе турында хәбәр ителә: "Гомәр бин әл-Хаттаб янына Йәмәннән өстәмә гаскәр килгән саен, ул алардан: "Арагызда Увәйс бин Әмир юкмы?"- дип сораган. Һәм шулай соравын Увәйс (р.г.) белән очрашканга кадәр дәвам иткән. Ул: "Син Увәйс бин Әмир буласыңмы?" - дип сорагач, Увәйс: “Мин”, - дип җавап бирә. Гомәр (р.г.) яңадан сорый: "Син мурад кабиләсенең каран нәселеннәнме?" Ул: “Әйе”,- дип җавап кайтара. “Син махау (проказа) авыруыннан (бер дирһәм зурлыгындагы урыныңнан кала) тулысынча терелә алдыңмы?” Ул: “Әйе”, - дип җавап бирә. Гомәр яңадан сорый: “Синең әниең бармы?” Ул: “Әйе”, - дип җавап бирә. “Миңа Рәсүлебез (с.г.в.) өстәмә гаскәр белән Йәмәннән мурад кабиләсенең каран нәселеннән, махау авыруыннан бер дирһәм зурлыгындагы урыныннан кала тулысынча терелгән Увәйс бин Әмир киләчәк, ул әнисен бик хөрмәт итә, ә Аллаһы Тәгалә белән ант иткәндә Аллаһы Тәгалә аңа булыша, әгәр дә булдыра алсаң, син аннан Аллаһы Тәгаләдән сине кичерүен үтенүен сора, дип әйтте, - ди Гомәр. - Аллаһы Тәгаләнең мине кичерүен сора!” Увәйс Аллаһы Тәгаләдән Гомәрне кичерүен сорый. Моннан соң Гомәр аның кая барырга теләвен сорый. Увәйс Куфага барырга теләвен әйтә. Гомәр: “Куфа башлыгына синең өчен хат языйммы?” - дип сорый. Увәйс аңа: “Миңа ярлылар арасында булу күбрәк ошый”, - дип җавап бирә. Икенче көнне Гомәр белән Куфа шәһәренең хаҗ кылган бер күренекле кешесе очраша һәм анардан Увәйс турында сораштыра башлый. Бу кеше аңа: “Мин аны соңгы тапкыр күргәндә, аның өендә бернәрсә дә юк иде дияргә була”, - ди. Гомәр: “Мин Рәсүлебезнең (с.г.в.) өстәмә гаскәр белән Йәмәннән мурад кабиләсенең каран нәселеннән, махау авыруыннан бер дирһәм зурлыгындагы урыныннан кала тулысынча терелгән Увәйс бин Әмир киләчәк, ул әнисен бик хөрмәт итә, ә Аллаһы Тәгалә белән ант иткәндә Аллаһы Тәгалә аңа булыша, шуңа күрә әгәр дә булдыра алсаң, син аннан Аллаһы Тәгаләдән сине кичерүен үтенүен сора, дип әйткәнен ишеткәнем бар”, - ди. Бу кеше Увәйс янына килә һәм Аллаһы Тәгаләдән аны кичерүен үтенүен сорый. Увәйс аңа: “Син хаҗны миннән соң кылдың, шуңа күрә Аллаһы Тәгаләдән син минем өчен сора”, - дип җавап бирә. Бу кеше: “Син Гомәр белән очраштыңмы?” - дип сорый. Увәйс: “Әйе”, - дип җавап бирә һәм Аллаһы Тәгаләдән бу кешене кичерүен сорый. Бу турыда кешеләр ишетәләр, ә Увәйс үз юлы белән китеп бара (Мөслим).

> ***“Чынлыкта табигыйннарның иң яхшысы – әнисе булган, элек бөтен тәне аклык белән капланган Увәйс исемле кеше. Аннан Аллаһы Тәгаләдән сезне кичерүен үтенүен сорагыз!”***

Бу хәдисне шулай ук Мөслим китергән икенче төрендә болай дип әйтүе хәбәр ителә: “Гомәр (р.г.) янына Куфадан кешеләр килә, араларында еш кына Увәйстән көлә торган кеше була. Гомәр: “Арагызда каран нәселеннән кеше бармы?” - дип сорый. Шул кеше алга чыгып баскач, Гомәр дәвам итә: “Аллаһы Тәгалә Илчесе (с.г.в.) болай диде: “Яныгызга Йәмәннән әнисеннән башка беркеме дә калмаган Увәйс исемле кеше киләчәк. Элек аның бөтен тәнен аклык каплаган була, Аллаһы Тәгаләгә мөрәҗәгать иткәч, Ул бер дирһәм зурлыгындагы урыныннан кала аның тәнен сәламәтләндерә. Аны очратканнар, анардан Аллаһы Тәгаләдән сезне кичерүен үтенүен сорасын”.

Бу хәдиснең Мөслим китергән өченче төрендә Гомәрнең (р.г.) болай дип әйтүе хәбәр ителә: “Минем Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): “Чынлыкта табигыйннарның иң яхшысы – әнисе булган, элек бөтен тәне аклык белән капланган Увәйс исемле кеше. Аннан Аллаһы Тәгаләдән сезне кичерүен үтенүен сорагыз!”

Сөбханалла! Нинди матур мисал! Аллаһы Тәгалә сезгә әти-әниегезне яратырга һәм аларның хакларын сакларга булышсын!

# БАШКАЛАРНЫҢ КӨФЕРЛЕГЕННӘН КАНӘГАТЬ БУЛУ — КӨФЕРЛЕК

**СОРАУ.** ***Миңа яңа туган баланың җиденче көнендә чәчен алу кирәклеге турында әйткәннәре бар. Бу күркәм эш буларак бәяләнә икән. Минем шуны беләсем килә: әлеге мәсьәләгә карата хәнәфи мәзһәбе галимнәре нинди фикердә тора?***

**ҖАВАП.** Хәнәфи мәзһәбеннән кала, Әһле Сөннәткә караган башка мәзһәбләрдә (мәлики, шәфигый, хәнбәли) яңа туган баланың җиденче көнендә чәчен алуның мөстәхәб (саваплы) гамәл булуы әйтелә. Алынган чәч авырлыгында көмеш яки алтын, яки аның бәясенә торган акчалата күләмдә сәдака бирү дигән әйбер дә бар.

Безнең галимнәребезнең (ягъни хәнәфи мәзһәбенең) фикере буенча, яңа туган баланың җиденче көнендә чәчен алу мөбах гамәл булып санала (рөхсәт ителгән, ләкин сөннәт тә, ваҗиб тә түгел) (“Әл-Фәтава Әл-Һиндия” китабының (6 нчы том) 371 нче битендәге “Әл-Фәтава Әл-Баззазия”дән).

◆

**СОРАУ.** ***Коръәни-Кәримнән алынган юлларны стеналарга язарга мөмкинме? Ислам дине белән кызыксынучы мөселман булмаган кешегә Коръәнгә тотынырга ярыймы һәм аны Коръән һәм фикъһ фәннәренә өйрәтү рөхсәт ителәме?***

**ҖАВАП.** Кайбер галимнәр стеналарга Коръәни-Кәримнән юллар алып язуның рөхсәт ителгән булуы турында әйтә. Башка галимнәр исә, вакытлар узу белән стеналарның аяк астына аву мөмкинлегеннән куркып, моны мәкруһ (хупланмый торган) гамәл дип саный. Бу хакта “Фәтава Кадыйхан” китабында әйтелгән.

Идәнгә җәелә торган әйберләргә (мендәр, палас һ.б.) Коръәннән юллар алып язу мәкруһ гамәл булып санала. Бу хакта “Әл-Гараиб” китабында әйтелгән.

Әбу Хәнифә болай дигән: “Мин христианга фикъһ һәм Коръән фәннәрен укытачакмын, һәм, бәлки, ул тугры юлга басар, әмма ул аңа кагылырга тиеш түгел. Әмма ул госел коена икән, бу чакта кулына Коръәнне алырга рөхсәт бар”. Бу хакта “Әл-Мөлтәкать” китабында әйтелгән.

◆

**СОРАУ.** ***Әгәр дә кеше дингә ышанмау, Аллаһны танымау сүзләрен ишеткәндә шул көфер сүзләрдән көлсә, бу аның көферлеккә төшүен аңлатамы? Әгәр кем дә булса үзенең танышының әлегә кадәр ислам динен кабул итмәгәнлегенә канәгать булып шатлыгын белдерсә, бу ничек бәяләнәчәк?***

**ҖАВАП.** Могтәбәр “Гүрар вә Дүрар” дип исемләнгән китапта (авторы Мулла Хөсрәү) болай диелә: “Әгәр кем дә булса көфер (Аллаһны инкяр итү, Аны танымау кебек) сүзләр ычкындырса һәм моны ишеткән кеше көлә башласа, ул шулай ук (аларны әйткән кеше кебек үк) көферлеккә төшәчәк. Әгәр дә сүзләр кеше үзенең көлүен тыеп тора алмаслык дәрәҗәдә көлке булса, ул көферлеккә төшми (кеше барлык очракларда да ишеткән көфер сүзләрне кабул итмәскә тиеш)”.

Икенче сорауга килгәндә исә шушы ук китапта бу турыда болай диелгән: “Заһир” китабының авторы: “Әбу Хәнифәдән тапшырыла: “Башкаларның көферлегеннән канәгать булу – көферлек”, – дип әйткән”.

**Татарстан мөфтие Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН**

# "ДИНСЕЗ ТӘРБИЯ – ТӘРБИЯСЕЗЛЕК"


**Гыйнвар аенда бөек татар галиме, мәгърифәтче, журналист, ислам дине тәгълиматчысы Ризаэддин Фәхретдиннең тууына 155 ел тулды. Әлеге вакыйга уңаеннан республика авыл-шәһәрләрендә төрле чаралар узды.**

Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институтында да "Ризаэддин Фахретдин һәм татар мәгърифәтчелеге" дип аталган Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе булды. Конференция эшендә катнашырга республиканың 22 районыннан, Оренбург өлкәсеннән укучылар һәм укытучылар, Татарстан, Башкортстан, Самара өлкәсеннән дин әһелләре һәм галимнәр килгән иде.

"Р.Фәхретдин мирасын өйрәнүдәге иң яхшы эшләр" конкурсында җиңеп чыккан укучыларны, студентларны бүләкләгәннән соң галимнәр бөек мәгърифәтченең эшчәнлеге, дин тәгълиматчыларының татарның рухый үсешенә керткән өлеше турында бай әчтәлекле чыгышлар ясадылар. Конференциянең хөрмәтле кунагы Татарстанның баш казые Җәлил Фазлыев чыгышын Ризаэддин Фәхретдиннең: "Динсез тәрбия – тәрбиясезлек" дигән сүзләре белән башлап, аның хезмәтләренең бала тәрбияләүдәге роленә тукталды.



*Бүгенге сәхифәдә, Аллаһы Тәгалә шушы шәригать хөкемнәренең асылын аңлап, көндәлек тормышыбызда үтәп барырга ныклы иман һәм сабырлык бирсә иде, дигән теләк белән Ризаэддин хәзрәт Фәхретдиннең "Тәрбияле бала" әсәреннән бер өзек тәкъдим итәбез. Балаларыгыз белән бергәләп укыгыз.*



## Ризаэддин ФӘХРЕТДИН

Ризаэддин Фәхретдин 1859 нчы елның 17 нче гыйнварында Әлмәт районының Кичүчат авылында дөньяга килә. Башлангыч белемне әтисе Фәхретдин хәзрәттән һәм әнисе Мәүһүбә абыстайдан ала, аннары мәдрәсәдә укый. Сәләте белән аерылып торган Ризаэддин Фәхретдин, яшь булуына карамастан, хәлфәлек итә башлый. Яңа алымнар белән укытуы турындагы даны тиз арада тирәякка тарала. Утыз яшендә Уфага чакырып китереп, аны казый итеп билгелиләр. Галим баш-аягы белән тарихи-фәнни эшкә чума, бик күп иҗат итә. Ул барлыгы 147 китап чыгара, аларның 77 се педагогикага багышланган.

Татар, ислам дөньясында танылган шәхесне 1906 нчы елда атаклы Рәмиевләр Оренбургка эшкә чакыралар. Ул "Шура" журналында мөхәррирлек итә, шул ук вакытта "Хөсәения"дә укытып, аның директоры булып та эшли. Журналда галимнең тарих, фәлсәфә, география, психология, икътисад, педагогика, биология, математика, татар теле һәм әдәбиятына кагылышлы 800гә якын мәкаләсе басыла.

Октябрь революциясеннән соң ул Уфага кайтып, яңадан казый булып эшли башлый. Галимҗан Баруди вафатыннан соң Үзәк диния нәзарәтенең мөфтие вазыйфасын үз өстенә ала. Дингә каршы көрәш барган, дин әһелләре кулга алынган, эзәрлекләнгән чорда Ризаэддин Фәхретдин аларны яклап, ил җитәкчелегенә хатлар яза. Көндезен мөфти мәшәкатьләре белән мәшгуль булса, кичен мөфтиятнең архивын рәткә сала, язу эшен дә туктатмый. Ачлыкта яшәгәндә дә бер генә кульязмасын да сатмый, бәяләп бетергесез мирасын киләчәк буын өчен саклый. Аның "Асар" дигән әсәрен бүгенге галимнәр татар дөньясы энциклопедиясе дип бәяли.

# АТА ВӘ АНА

1. Әй хөрмәтле балалар! Хезмәт күрсәткән кешеләр, яхшы күңелле кешеләр, һәрвакыт хөрмәттә булырлар вә якын күрелерләр, моны исә үзегез дә беләсездер. Хәлбуки сезнең ата-аналарыгыз сезгә иң авыр вә мәшәкатьле хезмәтләрен ителәр вә һаман да итәләр. Һәрвакыт сезне кайгырып, сезнең бәхетегез өчен тырышалар вә һәрвакыт сезнең өчен Аллаһы Тәгаләгә ялваралар вә дога кылалар. Моның өчен һәрникадәр аларның хезмәтләренә карышмавыгыз вә мәшәкатьләренең хакын түләвегез мөмкин булмаса да – һаман аларга ихлас белән хезмәт итүче вә аларга хөрмәт күрсәтүче булыгыз!..

2. Хосусан Аллаһы Тәгалә хәзрәтләре, аларга гүзәл мөгамәлә күрсәтүне васыять иткән вә иң изге Рәсүл әфәндебез (Аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер догасы һәм сәламе булсын!) хәзрәтләре: "Ата-аналарны риза итүче балалардан Аллаһы Тәгалә дә риза булыр", - дигән мәгънәдә сүз сөйләгән.

3. Киләчәк көндә, хөрмәтле вә файдалы кешеләр булуыгызны ата вә анагыз һәрвакыт өмет итеп торалар вә Аллаһы Тәгалә хәзрәтеннән сорыйлар. Инде сез дә мондый изгелекләргә каршы явызлык итүчеләрдән булмагыз! Һәм дә аларның нәсыйхәтләрен куркып вә өркеп түгел, бәлки мәхәббәт вә ихлас белән тотыгыз, чөнки алар бу дөнья хәлен озын тәҗрибәләре белән бик яхшы таныйлар вә сез белмәгән күп серләрне беләләр.

4. Кешенең итагатьле (буйсынучы) булуы – күңеле яхшы булу галәмәтедер (билгеседер). Инде сезгә иң якын кешеләр дә, әлбәттә, ата вә аналарыгыздыр. Шуның өчен аларга һәрвакытта итагатьле булыгыз. Гамәл вә сүздә аларга каршы килмәгез, бу сәбәптән аларның күңелләре дә рәхәтләнер, үз күңелләрегез дә вә дөньяда торуыгыз да гүзәл булыр.

5. Ата вә аналарыгыз хозурында бик әдәпле булыгыз, аларның сүзләрен яхшы тыңлагыз, ишарәләрен аңлагыз, алар белән артык кычкырмыйча, әдәпле итеп, ачык сөйләшегез. Алар аягүрә торганда, сез утырып тормагыз!..

6. Баһадирлык – адәм балаларында хөрмәтле бер сыйфаттыр. Олылар мәҗлесендә булып, алардан хикмәтле сүзләр ишетү гакылны арттыра вә гыйлемлекне күбәйтәдер. Хәтта кечкенә балаларны бөек адәмнәр мәртәбәсенә якын китерәдер. Шуның өчен йөрәксез балалар кебек аталарыгыз сөйләшеп утыруында катнашудан курыкмагыз вә белмәгән һәм аңламаган нәрсәләрегезне алардан сорагыз вә һәрнәрсәнең асылын белергә тырышыгыз!

7. Урамда йөргән вакытларыгызда атагыз очраса, аңа һәм аның белән берлектә булганнарга сәлам биреп әмерләрен көтеп торыгыз! Әгәр дә утырып торган вакытыгызда килсә – ачык йөз белән аягүрә торыгыз!..

8. Атагыз һәрнәрсә бирер булса – үзенең мәрхәмәте белән бирер, шуның өчен нәрсә булса да сораган вакытта янында чит адәмнәр булмаган вакытта сорагыз, әгәр дә теләгән нәрсәләрегезне бирмәсәләр – күп борчымагыз, чөнки сезгә нәрсә кирәк вә нәрсә кирәк түгел икәнлеген вә сезгә нинди әйберләр яраклы булып,ниндиләре яраклы булмавын алар тагын бик яхшы белерләр.

9. Атагызның иң якын дусты булса да, атагыздан башка кешедән кирәк әйберегезне сорау гаеп эш вә гаилә хөрмәтен җибәрүдер. Шуның өчен барлык теләгән әйберләрегезне атагыздан сорагыз!

10. Бала чагында акча тотарга өйрәнмәгән кеше – олы гайгач та акча тота белмәс, дөньяда гүзәл көн кичерә алмас, бәлки бар байлыгын исраф итеп бәхетсез булып калыр. Шуның өчен атагыз тарафыннан бирелгән акчаларны тота белергә өйрәнегез. Сак булыгыз, бу – аз акча гына, дия күрмәгез, чөнки бүген сезнең кирәкләрегез дә бирелгән акча кебек аздыр.

11. Кайбер балалар булыр ки: аталарының малларына ышанып, һичбер кәсеп вә эш юлына кермәсләр, бәлки ялкаулыкка гадәтләнерләр. Ахырда бер көн килер, акчалары да бетәр. Тереклек итәр өчен кулда һөнәр дә булмас. Шуның өчен ата малына ышанып тормыйча, бәлки никадәр бай баласы булсагыз да булыгыз, үзегезне кеше баласы санап, һөнәр өйрәнергә тырышыгыз!

12. Дөньяда торган вакытта шатлыкларны сөйләр, кайгыларны чишеп әчне бушатыр өчен иң якын, иң ышанычлы бер кешегә мохтаҗ булынадыр. Ләкин бу эшләр тугрысында ата белән анадан артык һичкем булмас, чөнки болар баланың шатлыгы өчен хәтта үзеннән артык сөенәдер вә хәсрәтләре өчен кулдан килгән барлык чараларны күрүдә кимчелек итмәсләр. Шуның өчен серләрегезне боларга сөйләгез, серләрегезнең хәзинәләре һәрвакытта ата вә аналарыгызның күңелләрен булдырсын!

13. Күзгә күренгән бернәрсәгә кызыгучы булмагыз, аналарыгызның җыеп куйган нәрсәләре вә кунаклар өчен дип хәзерләнгән әйберләре янында йөрмәгез вә зарар итмәгез! Чөнки аналарыннан рөхсәтсез мондый эшләр эшләүче балалар моның кебек эшләргә гадәтләнерләр вә, көннән-көн арттырып, ахырында (Аллаһы Тәгалә сакласын!) угры булырлар.

14. Бәдәнегез үсеп көч кергәч тә, кулларыгыздан килгән эшләрдә ата вә аналарыгызга ярдәм итүче булыгыз, бәлки шәфкать вә хезмәтләрегезне тагын да арттырыгыз, алар исә сезнең яшь вакытларыгызда вә иң зәгыйфь булган көнегездә тәрбияләп сезне үстергәннәр. Бер көн җитәр сез дә ата булырсыз, исәпләп карагыз, шул көндә балаларыгыз хөрмәтегезне сакламасалар, риза була белерсезме? Иң изге Рәсүл (Аңа Аллаһы Тәгаләнең хәер догасы һәм сәламе булсын!) әфәндебез хәзрәтләре: "Аталарыгызга изгелек итегез, сезгә балаларыгыз изгелек итәр", - дигән мәгънәдә бер сүз сөйләгән.

15. Кайбер балалар булыр ки: аталарының тәрбияләрендә вә мәрхәмәтләре кулъгәсендә рәхәтләнеп үсәрләр дә, үскәннән соң аталарының фикерләренә каршы килерләр, сүзләрен ишетмәсләр, аларның гамәлләрен аз күреп көләрләр. Сез шулай инсафсыз булмагыз! Аталарыгыз исә сезнең турыда җаваплы булмый, бәлки алар турысында сез җаваплы булачаксыз. Замана көннән-көн алга барып вә гыйлемнәр артып торганлыктан, бу көндәге бөек бер галимнең иртәге көндә бер шәкерт дәрәҗәсендә калачагы табигыйдер. Өч катлы бина салу тугрысында булган мактау өченче катны бина кылучыларга булган кебек, нигезне салучылар да гаепләнергә тиеш түгелләр.

16. Тиешсез бер эшкә кушкан вакытларында һич тыгызланмыйча вә күңелләрне җәрәхәтләндермичә, бәлки әдәп вә инсаф белән эшнең турысын белдерергә тырышыгыз!

# ИСЛАМ ДИНЕН ӨЙРӘНҮ АВЫР ТҮГЕЛ, ХАК МӨСЕЛМАН БУЛУ КЫЕНРАК



**Әгәр кешеләр, Аллаһ ризалыгы өчен бергә җыелып, Раббыбызның боерганын тормышка ашырырга, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) киңәшләрен тотып нинди дә булса гамәл кылырга җыеналар икән, аларга Аллаһы Тәгаләнең ярдәме һичшиксез киләчәк. Коръәни-Кәримдә әйтелә: "Әйт аларга... Мин сезне Аллаһ каршына икешәрләп яки берәмләп басарга, киңәшергә, уйларга чакырам. Ахирәттә булачак каты газап хакында алдан кисәтәм..."** *("Саба" сүрәсе, 46 нчы аять.)*

Ислам динен дәгъвәт кылу, бигрәк тә остаз исемен йөртү зур җаваплылык сорый. Мәчеткә укыйм дип очраклы кеше килеп керми. Ниндидер сәбәпләр белән аны Аллаһы Тәгалә китергән. Кемдер зур тормыш юлын узып, Коръән серләрен өйрәним дип килсә, кайсын зур кайгы китерә, кемдер баламны китергән җирдән аз гына тыңлыйм да китәм, дип килеп керә. Остазга һәркайсын тыңлый белү, аның дәрәҗәсендә сөйләшә белү мөһим. Беренче елдан ук шәкерт остазны калебе белән кабул итә һәм остазына холкы белән ошый бара. Остазның бурычы тәҗвид кагыйдәләрен өйрәтү генә түгел, ә гыйбадәт аша Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) мирасын тормышта файдаланып фикерләргә, әдәп вазыйфаларын үтәргә өйрәтү, Аллаһы сөбханә вә Тәгаләгә якынаюга юнәлтү.

Шәкертнең үзенә һәм җәмгыятькә зарар китерә торган гадәтләреннән арынырга ярдәм итү дә мөһим. Түтәлендә син теләгән җиләк үссен өчен чүбен утарга, ашлама кертергә кирәк. Динне бу дөньяда яшәү дәверендә бердәнбер туры юл дип калебенә сеңдерүгә сәбәпче булуга ирешергә тиешбез. Моның өчен иң элек мөгаллимәгә үз холкын үзгәртү, нәфесен җиңү өстендә эшләү мөһим. Төрле әзерлектә, төрле яшьтәге шәкертләр белән уртак тел таба белүдә, уку-укыту методикасын үзләштерүдә мөгаллимәләргә ярдәм кирәк. Ризаэддин Фәхретдиннең: "Әгәр бәндә үзенә Аллаһы Тәгалә бүләк иткән, йөрәгенә сеңдерелгән кодрәтне вә ихтыярны яхшы эшләргә сарыф итсә, Аллаһы Тәгалә шуны холык итә. Әгәр бозык эшкә сарыф итсә, Аллаһы Тәгалә шул бозык эшне холык итә", - дигән сүзләрен остаз үзенә һәм шәкертләренә кулланма итеп алса, остаз буларак та, мөселман буларак та җәмгыять алдында, өммәте алдында бурычын үтәгән булыр.

Аек акыл белән, дөрес юнәлештә фикерләү өчен гыйлем кирәк. Сөекле Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) Мөгаз бине Җәбәлгә биргән киңәшләрен истә тотыйк: "Кайда гына булсаң да Аллаһыдан курык, начар эштән соң яхшы гамәл кыл. Кешеләр белән мөнәсәбәтләрдә яхшы әхлаклы бул". Тагы бер хәдисне онытмыйк: "Күркәм иман ул - яхшы холык".

"Көферлек, икейөзлелек, рия, мактау сүзен ишетергә теләү, тәкәбберлек, хөсетлек, үзең өчен генә яшәү кебек сыйфатлардан йөрәгеңне пакьләмәсәң, синең тышкы күренешең белән театр куюыңда үзең һәм башкалар өчен берни файда булмас", - дип яза Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдин һәм изгеләр догасын тәкъдим итә: "Әй, Раббым Аллаһ! Тышкы яктан үзгәреп, эчке яктан үзгәрмичә башка кешеләрне үзгәртергә тырышудан үзеңә сыгынамын".

Камиллеккә, Аллаһка якынаюга Раббыбызның әмерен үтәп кенә ирешә алабыз. "Әй, иман китергән колларым! Аллаһы Тәгаләне еш-еш искә алып, дәвамлы зикер итегез. Иртән һәм кичен тәсбих әйтеп, Аңарга зикердә булыгыз" ("Әхзаб" сүрәсе, 41-42 нче аятьләр.)

Мәчетләрдә башлангыч белемне фидакарь мөгаллимәләребез бирә. Моннан биш-ун ел элек алар югары мөселман мәдрәсәләрендә белем алдылар. Күбесе шуның белән туктап калды. "Бишектән ләхеткә кадәр белем алыгыз", - диде сөекле Пәйгамбәребез (с.г.в.). Мәчетләрдә имам-хатыйб билгеләп куйган өлкән абыстай атна саен 1-2 сәгатькә мөгаллимәләрне зикергә, киңәшкә җыеп, үзләренең дә белемнәрен арттыруны бер юнәлешкә куйса, нәтиҗәсе булыр, иншә Аллаһ.


Безгә хәдисләрне, сираны, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддин, М.Бигиев һәм, гомумән, галимнәрнең хезмәтләре белән танышуны, милли тарихыбызны укытуны оештырсак, остазларыбыз өчен халкыбыз алдында кызарырга туры килмәс. Бигрәк тә өлкән остаз, Р. Фәхретдин хәзрәтнең "Адабе тәгълим" китабын кабат-кабат укып, андагы тәкъдимнәрне мөгаллимәләргә тормышка ашырырга булышса, нәтиҗәсен күреп, куанырлар иде. Кайбер дәресләргә, мәсәлән, тарихны бер кыска курс итеп бирергә югары уку йортларыннан укытучы, РИУдан шәкерт тә килә алыр иде (аларга сәдакалар да бирсәгез, белем дә килер, савабы да булыр, иншә Аллаһ).

Кайсы юнәлештә көчләрәк, шул фәннәрне мөгаллимәләр үзләре дә алып бара алалар. Мисал өчен генә китерәм. Гадел мәчете мөгаллимәләре 2012-2013 нче уку елында "Ислам һәм психология" курсын, Н.Т.Османның "250 хәдис" китабыннан хәдисләр укыдык. 2013-2014 нче уку елында хәдисләр өйрәнүне дәвам итәбез. Бер мөгаллимәбез РИУда тарих фәне курсларында укыган иде, быел безгә шуны укыта.

Тагы бер мөһим мәсьәлә бар. Мөгаллимәләребез "вакуумда", динебезгә кагылган вакыйгалар йә гайбәт рәвешендә, йә дөньяви газеталар аша гына килеп ирешә. Имам-хатыйб та, атнага бер тапкыр мөгаллимәләр җыенына кереп, мөфтият һәм мөхтәсибәтнең карарларын мөгаллим-мөгаллимәләргә вакытында ирештерсә, дөрес булыр иде. Халык белән күбрәк мөгаллимәләр эшли, сораулар белән аларга мөрәҗәгать итәләр. Дини оешмаларыбызның бер "пульста" эшләвенә мөгаллимәләр үз өлешләрен кертергә һәрвакыт әзер. Ислам динен өйрәнү авыр түгел, хак мөселман булу кыенрак. Өстәвенә, бөтен белемле кеше дә остаз була алмый. Инде бу эшкә алынганбыз икән, Аллаһ ярдәменә таянып фикерләвебез, холкыбызны камилләштерү өстендә эшлик. Зикердә булып, Пәйгамбәребез (с.г.в.) догаларын кылып, олуг галимнәребезнең киңәшләрен өйрәнеп, һәркөн Аллаһы Тәгаләгә хезмәттә булсак кына милләтебезгә, өммәтебезгә файдабыз булыр.

**Фәния ҖӘЛӘЛИЕВА,**
**Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә,**
**Гадел мәчете мөгаллимәсе**

# БЕЛЕМНӘН МӘХРҮМ ЙӨРӘК – АВЫРУ ЙӨРӘК



**Белемнең һәм белем алуның яхшылыгына Коръәндә дәлилләр күп. "Әгәр дә алар шуның белән Пәйгамбәргә һәм җитәкчеләргә мөрәҗәгать итсәләр, моны файда чыгарырга сәләтле кешеләр генә аңларлар" ("Ниса" сүрәсе, 83 нче аять). Шулай итеп, Аллаһы Тәгалә галимнәрне Үзенең әмерләреннән кирәк булган нәрсәләрне чыгара алучылар дип атый. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйткән: "Хакыйкатьтә, галимнәр пәйгамбәрләрнең варислары, пәйгамбәрләр үзләреннән соң мираска динар да, дирһәм дә калдырмадылар. Алар бары тик белем генә калдырдылар". Мәгълүм булганча, Пәйгамбәрләрнең урыннары – иң бөек урын. Һәм мондый урындагы кешеләрнең варислары булудан да абруйлырак берни дә юк.**

Аллаһы Тәгалә әйткән: "Әгәр дә алардан бер җәмәгать дин белемен өйрәнүгә керешсә яхшырак булыр. ("Тәүбә" сүрәсе, 122 нче аять); "Әгәр дә үзегез белмәсәгез, белем ияләреннән сорагыз" ("Нәхел" сүрәсе, 43 нче аять).

Пәйгамбәребез галәйһиссәлам болай дигән: "Белем алу юлына аяк басучыга Аллаһы Тәгалә җәннәткә бару юлын җиңеләйтә" (Мөслим).

Әбу Дәрдә әйткән: "Хакыйкатьтә нинди дә булса мәсьәләне өйрәнү минем өчен төне буе намаз укудан яхшырак". Ул шулай ук: "Белемне тапшыручы һәм өйрәнүче - яхшылыкта милектәшләр", - дигән.

Шәфигый әйткән: "Белем эстәү – өстәмә намазлардан хәерлерәк". Фәтех Мәсили: "Әгәр дә дару бирмәсәң, авыру үлмимени?" - дип сораган. Кешеләр: "Үлә, билгеле", - дигәннәр. Ул: "Йөрәк тә шулай ук, өч көн буе аны хикмәт һәм белем белән тукландырмасаң, ул үлә", - дип әйткән. Чынлап та, белем һәм хикмәт йөрәк өчен ризык булып тора. Белемнән мәхрүм булган йөрәк авырый һәм аның үлүе котылгысыз. Ләкин кеше аны сизми, чөнки дөнья куу белән мәшгуль булуы аны бу сәләттән мәхрүм итә. Ибне Мәсгуть болай дигән: "Белем югалганчы сезгә белем алырга омтылырга кирәк. Ә белемнең югалуы белемне тапшыручылар вафатыннан соң булачак. Чөнки беркем дә белүче булып тумый, ә белем өйрәнү сәбәпле генә җыела".

Аллаһы Тәгалә әйткән: "Аллаһ китап бирелгәннәрдән: "Сез аны аңлатырга тиеш буласыз. Чөнки аны яшерергә ярамый", - дип вәгъдә алды ("Әл-Гыймран" сүрәсе, 187 нче аять). Әлеге аятьтә белгәнеңне башкаларга өйрәтү фарыз кылына.

Сөннәткә килгәндә, белем өйрәтүнең яхшылыгын раслау өчен Йәмәнгә җибәргәндә Пәйгамбәр галәйһиссәламнең Мөгазгә әйткән сүзләрен китерергә була: "Хакыйкатьтә әгәр дә Аллаһ синең аркылы бер генә кешене булса да туры юлга бастырса, синең өчен бу – кызыл (нәселле) дөяләргә ия булудан да яхшырак" (Бохари).

Мөгаз бине Җәбәл: "Белем алыгыз! Чөнки Аллаһ ризалыгы өчен белем алу – Аннан куркуның билгесе, белемгә омтылу – гыйбадәт, башкалар белән нәрсә дә булса өйрәнү – тәсбих, белем алу – җиһат, белемсезгә белем өйрәтү – сәдака, аңларлык кешеләргә белем тапшыру – Аллаһыга якынаю чарасы. Белем ялгыз вакытта әңгәмәдәш, дус булачак, дингә юлны күрсәтәчәк, авырлыкларга сабыр итәргә өйрәтәчәк. Белем сәбәпле Аллаһ кайбер кешеләрне җитәкче итеп куеп күтәрәчәк, башкалар аларга иярәчәкләр. Белем турында фикерләү – уразага, башкалар белән белем алу төнге намазга тиң. Ул кешегә Аллаһыга итагать итәргә, Аңа гыйбадәт кылырга, туганнар белән элемтәдә торырга, хәрам һәм хәләлне белергә булыша. Белем – идарәче, ә гамәл – аңа иярүче. Ул бәхетле кешеләргә бирелә, ә бәхетсез кешеләр аннан мәхрүм", - дип әйткән.

# АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ ЫШАНУ

Аллаһы Тәгаләгә ышану – Аның Берлегенә ышану, Аның башлангычы булмауга һәм үлемсез булуына инану. Ул камил, кимчелекләрдән пакь һәм үзенчәлекле илаһи сыйфатлар белән тасвирлана. Раббыбыз шушы дөньяны бар иткән һәм ул гына барлыкка китерү көченә ия.

## ТӘУХИД НӘРСӘ УЛ?

"Тәүхид" сүзе "бераллалык" дигәнне аңлата. Мөселманнар Аллаһы Тәгаләнең берлегенә ышана. Әлеге ислам тәгълиматының дөреслеген акыл белән дәлилләү бик ансат. Барлыкка китерүче бер генә була ала, чөнки алар икәү булып, нәрсә дә булса булдырырга теләсәләр, аларга форма мәсьәләсендә килешергә кирәк булыр иде. Бер-берсе белән килешә алмаган очракта, үзенең теләгәненә ирешә алмаганы башкасыннан көчсезрәк булып чыга. Димәк, ул алла түгел, чөнки алла зәгыйфь, көчсез була алмый. Әгәр инде алар һәрвакытта да берберсе белән килешә торган булса, бу очракта аларның икесе дә көчсез була. Чөнки аларның килешүчәнлекләре, ягъни нәрсәгә дә булса мохтаҗлыклары, компромисска килүләре көчсезлек галәмәте булып чыга.

Шулай итеп, тәүхид - Аллаһы Тәгаләнең чынлыкта да, Ул тасвирланган сыйфатларда да, Аның гамәлләрендә дә бернинди иптәшләре булмауны раслаучы тәгълимат. Икенче төрле әйткәндә, Аллаһы Тәгаләгә охшаган башка зат юк, Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларына охшаш сыйфатлы берәү дә юк, бары тик Аллаһы Тәгалә генә барлыкка китерә һәм юк итә, башка берәү дә моны эшли алмый. Аллаһы Тәгаләдән башка берәү дә дөньяны барлыкка китерә алмый, аның белән идарә итә дә алмый. Бары тик Ул гына табынырга лаеклы Зат. Бары тик Аллаһы Тәгаләнең генә шәригатьне, ягъни канунны барлыкка китерергә хакы бар. Аллаһы Тәгалә, башка затлардан аермалы буларак, бар яктан да җитеш.

Күпаллалык - Аллаһы Тәгаләгә иптәш табу ул. Гарәпчәдән күпаллалык "ширек" дип атала. Ширек – Раббыбыз ярлыкамый торган гөнаһларның иң зурысы һәм бердәнбере, күпаллалыкка ышанучылар җәһәннәмдә мәңге яначаклар. Аллаһы Тәгаләгә иптәш табучылар мөселман була алмый.

Шуңа күрә күпаллалыкта гаеплү - күз алдына китерә алмаслык иң куркыныч гаеп. Төпле белемнәрең булмаган килеш кешегә мондый гаеп тагарга ярамый, бигрәк тә ул кеше үзен мөселман дип йөрсә. Кемгәдер ширек сыман тоелган нәрсәләр алай булмаска мөмкин. Кайвакыт мөселманнар кирәксезгә юк кына нәрсәләрдә дә күпаллалык күрә башлыйлар. Хакыйкатьне табу өчен, белем туплау кирәк.

Вакыйгалар агышына Аллаһы Тәгаләдән башка берәүнең йогынты ясый алачагына ышану барлыкка килмәсен өчен, үзеңнең уй-фикерләреңне күзәтеп торырга кирәк. Юлны аркылы йөгереп чыккан кара мәче дә, йолдызларның билгеле тәртиптә урнашуы да, сихерчелек тә бернинди көчкә ия түгел. Аллаһы Тәгалә нәрсәнеңдер булуын теләсә, дөньядагы барлык кешеләр һәм җеннәр бергә җыелса да, аны тоткарлый алмаячаклар. Шуңа күрә дә мөселманнар еш кына: "Ләә хәүлә үә ләә куәтә иллә билләһ," – дип әйтәләр. Мәгънәсе: "Аллаһы Тәгаләдән башка берәүдә дә көч һәм куәт юк".

*("Ислам турында сөйләшик" энциклопедиясеннән)*

## Авыру һәм сызлануլардан укыла торган дога

**Тирмизи хәдисләр җыентыгындагы Әнәс бине Мәликнең риваяте буенча, Рәсүлуллаһ (с.г.в.) болай куша торган булган: "Берәр җирең авыртканда кулыңны шул җиргә куй да шушы доганы кабатла: "Бисмилләһи әгүзү би гыйззәт-илләһи үә кудрәтиһи мин шәрри мә әҗиду мин үәҗәгый һәзә" (Аллаһ исеме белән. Башыма төшкән бу авыруның көченнән Аллаһның бөеклегенә һәм кодрәтенә сыенам).**

**Төрле чор акыл ияләре тәрбия турында гаҗәп күп хезмәтләр язганнар. Без алар белән таныш. Хәтта ташка чукып язып калдырганнары белән дә. Ләкин ни гаҗәп, тәрбия темасы җәмгыять өчен көн үзәгендәге чишелмәгән мәсьәлә булып кала бирә.**

# ЯШЬ БУЫН НАМАЗГА ҖИҢЕЛ БӨГЕЛӘ

Һәрьяклап үсеш алган шәхес формалаштыруда фундаменталь нигез булып рухый мәдәният санала. Ә моңа тәрбияви чыганак булып дөньяда иң киң таралган диннәрнең берсе - әбибабаларыбыз ун гасырдан артык элек кабул иткән ислам дине торган. Бүгенге көндә җәмгыятебездә мәдәниятне, рухыйлыкны һәм әхлакны диннән башка саклап калып булмаячак, дигән фикер өстенлек итә. Без бүген зур ышаныч белән: "Ислами тәрбиягә альтернатива юк", - дип әйтә алабыз.

Мин үзем "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә читтән торып белем алдым. Әлхәмдүлилләһ, Апас районының Урта Балтай авылында ихлас тырышып, дин дәресләре укытабыз. Бер төркемдә кыз балалар, икенчесендә әниләр, апалар, әбиләр шөгыльләнә. Ә инде ир балалар һәм өлкән яшьтәге ирләрне махсус дини белеме булган, пенсиядәге укытучы Рашат хәзрәт укыта. Укулар Диния нәзарәте тарафыннан расланган укыту программасы буенча алып барыла. Мәчетебездә башлангыч дин гыйлеме буларак ислам дине гакыйдәсен, шәригать хөкемнәрен, гарәпчә уку, язу, Коръәнне тәҗвид белән уку, әдәп-әхлак дәресләре укытабыз. Балаларның яшь зиһене бу гыйлемнәрне тиз йотып ала. Яшь буыннар намазга да җиңел бөгелә. Укуларны атнага икешәр көн үткәрәбез. Уку елы октябрь аеннан майга кадәр дәвам итә. Шәкертләребез мәчеткә теләп йөриләр. Вәгазьләрне бик яратып тыңлыйлар. Хәләл белән хәрамны аерырга, ата-ана, күрше хакын белергә өйрәтәбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) һәм аның сәхабәләренең, аларга ияргән ихлас мөселманнар тормышы хакында сөйлибез. Чөнки балалар һәрвакыт үзләренә үрнәк алырдай кешеләрне эзли. Исламның бөек бүләк икәнлеген аңлатабыз.


Исламга килү балаларның тормыш рәвешен үзгәртә. Кием дә чиста-пөхтә, үз-үзен тотышы да үзгәрә, мәктәптә өлгереше дә яхшыра. Мәчеткә йөргән балаларыбызның йөзләрендә үзенә күрә бер сөйкемлелек, нур балкып тора. Кызларыбызның матур итеп бәйләгән яулыклары нур өстенә нур. Китаплар белән дә үзебез тәэмин итәргә тырышабыз. Чөнки гыйлем эстәүче шәкертләргә бирелгән сәдака иң әҗерлесе (бергә 7 мең әҗер) санала.

Балаларыбызга ислам тәрбиясе бирсәк кенә киләчәк буын сәламәт булачак, күңелләре Аллаһы Тәгалә йорты белән бәйләнгән бала ата-анасына картаймыш көннәрендә юаныч һәм бәхет чыганагы.

**Мөнирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
**Апас мөхтәсибәте**



# ДОГА – АЛЛАҺКА ШӨКЕР ИТҮДЕР



Дога чакыру, мөрәҗәгать итү, теләү, ярдәм сорау, исем кушу, ялвару, сыену дигән мәгънәләрне белдерә. Аңа мондый аңлатма бирергә мөмкин: "Дога, колның бөтен барлыгы белән Аллаһы Тәгаләгә юнәлеп, нәрсәнең дә булса үтәлүенә яки үтәлмәвен сорап, Аңа мәдхия укып, көчсезлек вә ихтыяҗ белән теләктә булу". Дога инсан белән Аллаһы Тәгалә арасында бер хәбәрләшү чарасы буларак та билгеләнә ала. Тыштан бу хәбәрләшү чарасы бер генә яклы кебек; фәкать догада гына аңлашыла торган бер юл белән Аллаһның җавап бирүенә ышаныч һәм өмет бар.

Вәхи – Аллаһ белән инсан арасында барган югарыдан түбәнгә, ягъни Аллаһтан инсанга юнәлгән бер шәхси аралашу. Дога исә инсан белән Аллаһ арасында барган, түбәннән югарыга юнәлгән бер төр шәхси сөйләшү. Дога инсанның Аллаһны чакыруы һәм Аңа сыенуы, Аллаһтан исә инсанга мәрхәмәт, бүләк һәм саклану чарасы буларак та аңлатыла ала.

Ислам буенча тормыш – Яралтучы белән яралтылган арасында бер элемтә булганга күрә, инсанның бөтен эшчәнлеге, үзе бу турыда уйламаса да, бер догадыр. Коръәндә бу болай аңлатыла: "Догагыз булмаса, Раббы сезгә ни өчен игътибар бирсен?" ("Фуркан" сүрәсенең 77 нче аяте). Дога ярдәмендә барган Аллаһ - инсан диалогында Аллаһ колына һичшиксез җавап бирер ("Гафир" сүрәсенең 60 нчы аяте). Аллаһ инсанга кан тамырыннан (аортадан) күпкә якынрак булу сәбәпле дога укыган инсанның кычкырып чакыруы, ачыргалануы, купшы сүзләрнең кирәге юк. Догада иң мөһиме сүзләр түгел, ә ихласлык һәм самимилектер.

Аллаһ Рәсүле (с.г.в.) Мәккәдән Таифкә исламга чакырырга китә. Таифтә аңа ташлар аталар, башын һәм аякларын яралыйлар. Кире кайтканда бер йөземлектә качып торганда ул шушы доганы укыган: "Аллаһым! Көчемнең көчсезлеккә әйләнүен, чарасыз калуымны, халык каршында кадерсез күренүемне фәкать сиңа күрсәтәм, сиңа шикаять итәм. Әй мәрхәмәтлеләрнең иң мәрхәмәтлесе! Җәберләнгәннәрнең Раббысы син!

Аллаһым! Мине холыксыз, намуссыз бер дошман кулына төшермә, хәтта тормышымның тезгеннәренә ия булган туганнан алып дуска кадәр мине мохтаҗ итмә, мәрхәмәтлесең. Аллаһым! Әгәр миңа ачулы түгелсең икән, башымнан уза торган бәлаләргә һич бирешмәм. Синең хакимлегең боларны күрсәтмәячәк кадәр киң. Сиңа сыенам. Синең йөзеңнең нурына сыенам. Бөтен караңгылыкны яктырткан, дөнья вә ахирәт эшләренең яхшыруы Аңа бәйле булган нурга сыенам. Аллаһым! Син разый булуга кадәр, кичерүеңне телим. Бөтен куәт, һәртөрле кодрәт фәкать синдәдер".

Доганың башы да, ахыры да Аллаһка шөкер итүдер.

**Рәуф ПӘХЛЕВАН ГҮР,**
**"Авыр вакытларда укыла торган догалар" китабыннан**

**Бөгелмә районы һәм Бөгелмә шәһәре мөхтәсибәте тарафыннан оештырылган "Зәйтүнә" II республикакүләм дини мөнәҗәтләр фестивале Россия ислам университеты талибы Сәед Дауднның Коръән аятьләре укуы һәм Татарстан мөфтие урынбасары, Бөгелмә районы һәм Бөгелмә шәһәре имам-хатыйбы Рөстәм хәзрәт Хәйруллинның хәер-фатихасы белән башланып китте.**

# ИЛ ЯШӘВЕ – МОҢ БЕЛӘН




Матур традициягә әйләнеп бара торган бу күркәм чараның быел географиясе киңәя төшкән, катнашучылары сан ягыннан арткан: Казан, Зәй, Яңа Чишмә, Баулы, Лениногорск, Урыссу, Әлмәт, Бөгелмәдән һәм районыбызның Карабаш бистәсеннән, Кодаш, Татар Димскәе, Иркен авылларыннан мөнәҗәт әйтүчеләр катнашты. Бәйгедә катнашучылар дүрт төркемдә бәяләнделәр: 17 яшькә кадәргеләр; 18-40 яшьлекләр; 40 яшьтән өлкәнрәкләр - ялгыз башкаручылар һәм ансамбльләр чыгышлары.

Жюри әгъзалары да бик мәртәбәле затлар: Татарстанның халык артисты Миңгол Галиев, Татарстан мөфтие урынбасары Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе Айнур Әхмәтшин, Казан консерваториясе өлкән укытучысы Илвир Низамов, Казаннан шәрык клубы җитәкчесе Эльмира Бәйрәмова конкурсантларга карата таләпчән, шул ук вакытта бик тә хәерхаһлы булдылар.

Бәйгене оештыру югары дәрәҗәдә тәэмин ителгән иде. Катнашучылар да, тамашачылар да игътибардан бик разый калып, оештыручыларга (таякның юан башы Бөгелмә мөхтәсибәтенең яшьләр белән эшләү бүлегенә һәм Татар мәдәният үзәге хезмәткәрләренә төште дип беләбез) ихлас рәхмәтләрен җиткерделәр.

Һәркем ныклы әзерлек белән килгән. Мәдәният үзәгенең ишеген ачып керүгә, сәхнәдә үзенә күрә имтихан тотачак мөнәҗәтчеләрне генә түгел, гади тамашачыны да дулкынландыргыч халәт чолгап ала. Бәйгенең балалар чыгышыннан башланып китүе күңелдәге рәхәтлекне көчәйтеп җибәрде. Иркен авылыннан килгән нәни кызчык Рәзинә Сабитованың: "Иртә-кичен укы Коръән", – дип сабыйларча ихласлык белән кабатлавы күңелләргә нәсыйхәт булып керерлек иде шул. Ә инде Диләрә Гафурова, Ильяс Минһаҗевларның мөнәҗәтләрне матур тавыш белән, бөтен мелизмнарын җиренә җиткереп көйләүләре "сөбханалла, бу балалар моны матур тавышлы булып, җырлый белгәнгә генә түгел, ә чын-чыннан иманлы бала булганга шулай башкаралар бит" диган уйга этәрде.




Урта буын башкаручылар арасында, беренче чиратта, ир-егетләрнең күплеге һәм аларның башкару осталыгы бер баш югары булу белән аерылып торды. Гаҗәп түгел, алар, нигездә, Казаннан килгән Россия ислам университеты талиблары иде. Аерым-аерым да, тәнәфесләр вакытында да кумәкләп һәм дуэт, яисә трио булып та төрекчә дә, гарәпчә дә чын илаһи мәкам белән мөнәҗәтләр көйләделәр, салаватлар әйттеләр. Егетләр күңелләр хушланганчы сәхнәдә булдылар, йөрәкләрне сафландырдылар, алар чыгышыннан агылган илаһи энергияне сүз белән әйтеп аңлата торган түгел.

Өлкәннәр арасындагы чыгышлар төрлелеге белән аерылып торды. Монда Сәгыйдә Гыймаева, Гөлгенә Авзалова, Фәния Сухова (өчесе дә Бөгелмәдән), Гаҗибә Миңлебаева (Лениногорск) кебек үзешчән артист буларак, гомерләрен сәхнә белән бәйләгән затлар да, күңел таләбенә буйсынып, кем әйтмешли, "үзе өчен генә" мөнәҗәт әйтүчеләр дә бар иде. Әмма "үзе өчен генә" дию аларның башкару осталыгын, тавышын, моңын һич кенә дә киметми, киресенчә, гадилеге, "безнеңчә" булуы белән йөрәкләргә тагын да тәэсирлерәк үтеп керә. Татар Димскәеннән Минира Ишмиева, Римма Низамоваларның, Кодаштан Равилә Арслановаларның чыгышлары кемне генә битараф калдырды икән!? Шуңадыр да залдан бертуктаусыз: "Машалла! Сөбханалла! Афәрин!" - кебек күтәрләү сүзләре тынып тормады.

Күмәк чыгышларның да берсен алып, берсен куярлык түгел иде: Бөгелмәнең "Мирас", Лениногорскиның "Ихлас" ансамбльләре, Урыссуның "Фәнис" төркеме, Казанның "Мәрҗани", "Бәрәкәт" төркемнәре мөнәҗәтләрнең бөтен гүзәллеген ачып салдылар, илаһи тәэсирен күрсәтә алдылар. Ә менә шәһәребезнең "Ишрак" һәм Яңа Чишмәнең "Рисалә" кызлары дини җырларны берничә тавышка башкарып, моң өстенә моң, нур өстенә нур өстәде.

Жюри рәисе Мингол әфәнде Галиев әйткәндәй, сәнгатьтә җиңүчеләрне спорттагы кебек секундка карап бәяләп булмый. Моң һәм моңлы аваз – һәркемнең үзенчәлекле, урын алучылар, нигездә, сәхнә тәҗрибәсе күбрәк булган, дулкынлануларын чак кына тирәнрәк яшерә алган затлар. Быелгыдай алгарыш белән колач җәйсә, киләчәктә фестивальдә чыгышларны бәяләү тәртибен бераз үзгәртү таләп ителәдәр: махсус әзерлекле, тамашачы алдында еш булып чарланган чыгыш ясаучыларны – аерым, ә инде табыннарда, башка сәбәпләр белән жыелган җәмәгать арасында иплe генә көйләп, чын милли моңнарны саф халыкча аһәң белән башкаручы, шул рәвешле бай мирасны милләттәшләребез арасында яшәтүче үзешчән мөнәҗәтчеләр өчен аерым номинация булдыру кирәктер, диган тәкъдимне дә җиткерде жюри әгъзалары.


Дини гореф-гадәтләрне торгызу елында республика күләмендә уздырылган шушы олы чараның географиясе алга таба тагын да киңәер һәм республика чикләрен үтеп чыгар дип ышанасы килә. Миңгол Галиев сүзләре белән әйткәндә: "Ил яшәве – моң белән. Быел яшьләрнең күплеге һәм аларның югары дәрәҗәдәге чыгышлары, чын мәгънәсендә, милләтебезнең киләчәге өметле икәнен күрсәтә".

**Әлфинур ШӘВӘЛИЕВА,**
**Бөгелмә.**







**"ДУМ РТ ХАДЖ" программасы җитәкчесе Хәбибулла НӘФИСУЛЛИН белән әңгәмәбезне без, үгезне мөгезеннән элэктереп дигәндәй, әнә шул сорауга җавап эзләүдән башладык. Юк-юкта, хаҗга юлламалар теге туроператорда алайрак икән, бусында бәясе дә кулайрак икән, дигән сүзләрне ишеткәләгән бар. Ә чынлыкта ничек соң?**



# МИН НИ ӨЧЕН "ДУМ РТ ХАДЖ"НЫ САЙЛЫЙМ?



- Хаҗга бару өчен квотаны төбәкләргә дәүләт бүлеп бирә. Билгеле бер күләмдәгесен Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте дә ала. 2012 нче елда Диния нәзарәте "Татарский деловой мир" компаниясе оештырып, менә инде өченче ел шушы оешма "ДУМ РТ ХАДЖ" программасын тормышка ашырып килә. Максатыбыз - хаҗиларны хәнәфи мәзһәбенә һәм татар халкы традицияләренә туры килмәгән чит идеологияләр йогынтысыннан саклап, хаҗ йоласын үтәүнең чисталыгына ирешү. Монысы - беренче сәбәп.

Икенчесе. Без хаҗиларны арзан бәяләр белән хәйләләп җәлеп итмибез. Тукландыру, ихрам, корбан (аны чалу, эшкәртү, корбан итен мохтаҗларга өләшү) белән тәэмин итү - болар барысы да хаҗ бәясенә кертелгән. Кайбер тур-операторлар арзанлы бәяләр белән кызыктыралар да, аннары хаҗ кылган чакта тегесе өчен, монысы өчен өстәмә акча таләп итә башлыйлар. Бездә андый нәрсә юк. Шуңа күрә хаҗи, хаҗ йоласының күпмегә төшүен аңлап, бәяне дөрес кабул итәргә тиеш.

Әйткәнемчә, "ДУМ РТ ХАДЖ" программасы хезмәт күрсәтүләрнең, сервисның минималь һәм җитәрлек күләмдәге комплексын үз эченә ала. Безнең программа шәһәр читеннән 20 шәр кешелек бүлмәле арзанлы кунакханәләр тәкъдим итми, шулай ук өч йолдызлы кунакханәләр дә каралмаган. Хаҗилар бер йолдызлы кунакханәләрдә, 8 әр кешелек (азрак та булырга мөмкин) уңайлы бүлмәләрдә яши. Ашату, корбан, ихрам, трансфер (автобуслар хаҗиларны биш вакыт намазга Әл-Хәрәм мәчетенә ташып тора) бар да шул суммага керә. Хаҗилар үзләре белән юлга сувенирга җитәрлек кенә акча ала.

***- Хаҗ кылырга ниятем булса, мин эшне нәрсәдән башларга тиеш?***

- Әгәр Казанда яшәсәгез, безнең офиска мөрәҗәгать итәргә яки телефон аша элемтәгә керергә кирәк: **+7 (843) 524-92-10, +7 (843) 240-53-98, +7 (843) 200-93-11, 8-800-555-92 -10.**

**Адресыбыз: 420021 Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт.**

**Интернеттагы сайт: www.dumrt-haj.ru.**

**Электрон почта адресы: 524910@mail.com.**

**Район җирлегендә яшәгән очракта төбәк агентларына – мөхтәсибләргә мөрәҗәгать итәсез.**

Аннан соң офиста яки агентлар белән килешү төзеп, шунда ук хаҗның тулаем бәясен түлисез. Элек өлешчә генә түләтә идек. Әмма хәзер вазгыять үзгәреп тора, доллар тотрыклы түгел.

***- Димәк, бәя артуның сәбәбе дә шунда...***

- Әлбәттә. Безнең чыгымнарның туксан проценты чит илләрдәге партнерларыбызга туры килә. Акчаны аларга долларда күчерәбез бит. Ә доллар соңгы ике ай эчендә генә дә 4 сумга кыйммәтләнде. Әгәр һаман шулай үсеп торса, хаҗ бәясе тагы да артырга мөмкин әле. Дөнья хәлен белеп булмый, шунлыктан хаҗиларны хәзердән үк аяк киенеп куярга чакырабыз.

***- Мин сезгә килер алдыннан хаҗиларның фикерләрен сораштым, сайтларны, матбугат чараларын карадым. Бигрәк тә узган елгы хаҗ сәфәреннән бик канәгать кайтканнар. Шулай да камиллекнең чиге юк, диләр. Хаҗның сыйфатын тагын да яхшырту өченниләр эшләргә уйлыйсыз?***

- Теләсә нинди уңыш – Аллаһы Тәгаләдән. Шушы ике ел эчендә, әлхәмдүлилләһ, шундый уңышка ирештек ки, Аңа чиксез рәхмәтлебез. Ничек итеп тагын да зуррак уңыш сорарга була инде! (Әлбәттә, без камилләшү ягында, мәсәлән, бәяләрне кимәртәләп арзангарак алу юлларын карыйбыз.) Хаҗиларыбызның да рәхмәттән башка бернинди канәгатьсезлек белдергәннәре юк. Алга таба да хаҗ сәфәрләрен бәла-казасыз, тыныч кына оештыру насыйп булса, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәрбез.

***- Сәфәрне шулай сыйфатлы итеп оештыруда төркем җитәкчеләренең дә өлеше бардыр...***

- Без аларны конкурс игълан итеп сайлап кына алабыз. Гарәп телен, хаҗ йолаларын белүеннән дә бигрәк төркем җитәкчесе бик җаваплы, оештыру сәләтенә ия булырга тиеш. Быел төркемнәрне 50 кешедән 45 кә калдырырга булдык, чөнки андагы автобуслар 45-47 кешелек, төркем икегә бүленмәсен, дидек. Минем хаҗиларга үтенечем бар: сәфәр вакытында төркем җитәкчеләренең кушканнарын төгәл үтәсәгез, тәртипне сакласагыз иде, бу үзегезнең үк иминлегегез, тынычлыгыгыз өчен кирәк. Алайса кайчагында шундый хәлләр дә була: сәгать 5 тә автобус белән кузгалабыз, дип игълан итәбез, ә әбиләребез сәгать 3 тән үк әзерләнеп чыгып утыралар. Сәгать 3 тәге автобус башка төркемне алырга килә бит. "Абыстайлар, без аңлыйбыз инде, сез совет чыныгуы алган. Әмма дә ләкин сәгать 5 тә дигәч 5 тә чыгарга кирәк",- дип җайлап аңлатырга туры килә үзләренә. Тагын бер мөһим нәрсә – сабырлык кирәк. Җиддәгә килеп төшкәч тә туристлар кебек кунакханәгә юл тоту юк анда. Документларны карап тикшергәнче байтак вакыт уза. Бу без оештырып җиткермәгәннән түгел, тәртибе шулай. Хаҗиларны зарыктырмас өчен болай да мөмкин булганның барын эшлибез.

**Әңгәмәдәш - Нәүбәһар КӘБИРОВА**





# Локман Хәким

## Локман Хәкимгә хикмәт килүе

Аллаһ Раббыбыз Коръәни-Кәримдә ("Локман" сүрәсе, 11 нче аять) әйтә: "Үә ләкаде әәтәйнәә Лүкомәәнәл хикмәтә әнишкүр лилләәһ, үә мәй йәшкүр фә иннәмәә йәшкүру линәфсиһ, үә мәң кәфара фә иннәллааһә ганиййүн хәмиидә", ягъни "Хактыр ки, Без Локманга, Аллаһка шөкер ит, дип хикмәт (ачык зиһен, зирәклек) бирдек. Шөкер иткән кеше үзе өчен шөкер итәр. Шөкер итмәгән кеше - шөкер итмәсен - Аллаһ аның шөкеренә мохтаҗ түгел. Аллаһ һәртөрле мактауга лаек".

Нәрсә ул хикмәт - зирәклек? Ул - Аллаһ биргән акылың ярдәмендә, алган гыйлемеңне тормышта дөрес итеп куллана һәм башкаларга җиткерә белү. Без үзебезне иманлы кеше дип саныйбыз, күбрәк изгелек кыласыбыз, савап җыясыбыз килә. Риваятьләрдә килә, Муса (г-м) Аллаһтан: "Син риза булсын өчен, рәхмәтеңә ирешү өчен нәрсә эшлим?" - дип сораган һәм Аллаһ Раббыбыз: "Бу бик җиңел, Мин биргән язмышыңа канәгать бул һәм шөкер ит", - дигән.

Иман китергәнбез икән, иманның бер шарты - тәкъдирнең яхшысы да, яманы да Аллаһтан булуга ышану. Без байлыгыбыз, дәрәҗәбез артса, безне мактасалар, бу эш үзебездән, дип уйлап, күңелдән горурлык үтә, я мактанып куябыз, шөкер итәргә онытабыз. Эш без уйлаганча барып чыкмаса, зыян күрсәк, тәнкыйтьләсәләр, түбән дәрәҗәгә төшерсәләр, зарланып, кемнедер гаепли башлыйбыз. Иманлы икәнсең - берәүне дә сукмә, канәгать бул. Бу Аллаһның тәкъдире дип кабул ит.

Аллаһның хәерсез эше юк. Һәр эш артында бер хәер-сөенеч бар. Кыямәт көнендә кешеләр: "Нишләп безне үпкәләтүчеләр, рәнҗетүчеләр күбрәк булмады икән?" - дип әйтерләр, ди. Чөнки нигъмәткә шөкер итү нигъмәтне арттыра, сабыр итү Аллаһка якынайта һәм савапны арттыра. Безнең әбиләр: "Хәерле каза хәерсез дәүләттән артыграк", - диләр иде. Шуңа күрә дә Аллаһ Раббыбыз аятьтә: "Шөкер итсен өчен хикмәт бирдек", - ди. Аллаһның нигъмәтенә шөкер итеп бетерерлек түгел, чөнки шөкрана үзе дә Аллаһның нигъмәте.

Гыйлеме хикмәт дәрәҗәсенә җиткән кеше генә авыр вакытларда үзен тыныч тота һәм шөкер кыла ала.

Локман Хәким кешеләрне әдәп-әхлакка чакырып вәгазьләгән вакытында, берәү аны күреп, бик гаҗәпләнеп: "Син кол идең, көтүче идең, ничек бу дәрәҗәгә ирештең?" - дип сораган. Локман Хәким: "Әйе, мин - син әйткән шул кеше. Мин беркайчан ялган сөйләмәдем, әманәткә хыянәт итмәдем, барына канәгать булдым, мал артыннан кумадым, үземә кагылмаган әйберләргә кысылмадым", - дип җавап биргән.

Алган гыйлемнәребез бездә шушы сыйфатларны булдыра алмаса, ул хикмәткә алып бармый, дөнья сазлыгына батырып безне һәлак итә.

Фөзәйл ибне Ияздан Һарун әр-Рәшит патша: "Бурычларың бармы?" - дип сорагач: "Падишаһым, бурычларым бик күп, әмма син аны түли алмыйсың", - ди. "Мин дә түли алмый торган нинди бурыч ул?" - дигәч: "Аллаһ каршында бурычларым бик күп. Шуларны түләү белән мәшгульмен. Кыска гына гомер өчен, Аллаһ биргәненә риза булмыйча, бурычка кереп әйбер алырга оялдым", - ди. Аллаһ каршында иң зур бурычыбыз - шөкрана кылу һәм канәгать булу. Биш вакыт намаз укып, намаз арасында зарланып, кешеләрне сүгеп йөрисең икән - бу шөкрана түгел. Син намаз дигән бурычны җилкәңнән төшердең - рәхмәт баскычына күтәрелә алмадың.

Локман Хәкимгә хикмәт бирелү тарихы да гыйбрәтле. Аллаһ Раббыбыз Үзенең фәрештәләре аркылы аңа пәйгамбәрлек һәм хәлифә булуны тәкъдим итә. Локман Хәким: "Сайлау мөмкинлеге бармы?" - дип сорый. Уңай җавап алгач, икесеннән дә баш тартып: "Миңа бәлаләрдән сәламәтлек, гафият (исәнлек, саулык) кирәк. Пәйгамбәрләргә пәйгамбәрлек белән бәла килгәнен беләмен, янә хөкем кылучы олуг бәла әчендәдер. Әгәр дөрес хөкем итсә, хуш. Әмма золым кылса, урыны җәһәннәм. Миңа дөньяда түбәнлек, хурлык кылыныл, ахирәттә газиз булу артыграк", - ди.

Пәйгамбәрлек һәм патшалыкка караганда гади кеше булуны артык күргәне өчен Аллаһ Раббыбыз аңа гыйлем һәм хикмәт бирә...

...Әйтәләр ки, Локман Хәким улына бер капчык гәрчич орлыгы санынча нәсыйхәт кылган. Аларны санап-язып бетерү мөмкин түгел. Монда аларның кайберләре. Һәркайсыбызга дөрес нәтиҗә ясарга, хаталардан сакланырга ярдәм итсә иде.

## Локман Хәким турында хикәятләр

* * *

Локман Хәкимнең ике хатыны булган. Берсенең - күзе, икенчесенең аягы зәгыйфь икән. "Син акыл иясе, ни өчен кимчелекле хатын алдың?" - дигән сорауга: "Хатын-кыз ирдән күркәмлектә, байлыкта, нәселдә - кимрәк, тәкъвалыкта артыграк булса хәерле. Күп вакыт чибәр хатын иргә түгел, ир аңа хезмәт итә, ир хатын колына әйләнә",- дип җавап биргән. Тарихка күз салсак та, дөньяларын тетрәткән падишаһлар чибәр хатыннары аркасында харап булган: Атилла, Александр Македонский һ.б. Төркиянең данлыклы Сөләйман патшасы да хатыны Роксалана алдында көчсез булган.

Акыллы кеше хатынны байлыгына, чибәрлегенә карап түгел, акылына, әдәбенә, тәкъвалыгына карап сайлый.

* * *

Локман Хәким ерак сәфәргә китәр алдыннан улына нәсыйхәт кылып әйткән: "Диңгез, ут, хатын-кыз - бер төрле. Алардан башка яшәү дә авыр, аларның нәрсә китереп чыгарасын да белеп булмый. Диңгезгә ышанычлы көймә белән кер, ут белән сак эш ит. Байлар, җитәкчеләр дә ут кебек, бик якынайма - янарсың, бик ерагайма - туңарсың. Сереңне хатыныңа сөйләмә".

Әтисе киткәч, улы аның сүзләрен сынап карамакчы була. Шәһәр башлыгының бер куштаны белән дуслаша, яңа байдан әҗәт ала, бер сарык суеп пешереп, капчыгына тутырып өенә алып кайта. Хатыны капчыкта нәрсә барлыгы белән кызыксынгач: "Әй минем сөекле хатыным, сахрада берәү белән ачуланыштык, үтерәп котылдым - югыйсә мине үтерә иде, зинһар, берәүгә дә сөйләмә, сиңа гына әйтәм", - ди. Көннәрдән беркөнне хатыны белән сүзгә килделәр. Хатыны әйтте: "Үзеңне бел, мин дигәнчә булмаса, үзеңне зинданга яптырам". Ире ачуланган булып хатынына сукты, шуннан хатыны өйдән йөгереп чыгып, каравыл кычкырды: "Минем ирем фәлән көнне берәүне үтерде, бүген мине үтермәкче була, коткарыгыз!" Халык җыелды, бу хәбәр шәһәр башлыгына ирешә. "Локман Хәкимнең улын зинданга ябыйк, кем алып килә?" - диде ул. Теге куштан дусты: "Үзем алып киләм, мин аны беләм", - дип, Локман Хәким улын алырга сакчылар белән килде. Ул ялварды: "Син бит минем якын дустым, бу бәладән качарга ярдәм ит", - диде. Дусты тыңламады, кулларын бәйләтеп алып китте. Моны ишеткән яңа бай тиз килеп җитте: "Тизрәк минем алачагымны бир", - диде. "Хәлем авыр, күрмисеңмени, бераз көтеп тор", - дигәч, ризалашмады, өеңне яндыртам, дип куркытты. Локман Хәкимнең улы әҗәтен кайтарды.

Шәһәр башлыгы янына алып килгәч, шәһәр башлыгы: "Әй, хөрмәтле кешенең улы, гаҗәп эш кылдың. Сиңа килешми, хөкем итеп җәзага тартабыз", - диде. Локман Хәкимнең улы әйтте: "Үлгән кешенең никадәр җәрәхәте булса, мине дә аннан артык җәрәхәт кылмый үтерегез", - диде. Хатыны сөенә-сөенә капчык яшерелгән урынны күрсәтте. Капчыкны шәһәр башлыгы янына алып килделәр, ачып карасалар - пешкән сарык ите. "Бу ни хәл?" - дип сорадылар. Локман Хәкимнең улы этисенең нәсыйхәтләрен тәҗрибә кылып каравын әйтте. Бу күпләр өчен сабак булды.

* * *

Локман Хәким кол вакытта хуҗасы аны бакчасына җимеш җыярга җибәрә. Барлык коллар күп итеп җимеш ашый, ләкин Локман Хәким ашамый. Рөхсәтсез ашаган җимеш хәрәм була, калебне каралта, ихтыяр көчен бетерә.

Юләрләр арасында бер акыллы булса, юләрләр аны диванага чыгарып көлә. Төрекмән язучысы Мәхдүмколый да бит: "Ишәкләр янында ишәк кебек бул, чын йөзеңне ачма", - дигән. Коллар да Локман Хәкимнән көлгән һәм кайткач сүз берләшеп: "Ул җимеш ашады", - дип хуҗага җиткергән. Бар шаһитлар да Локман Хәкимгә каршы. Хуҗасы ачуланып: "Сиңа нинди җәза бирим?" - дигәч, Локман Хәким: "Син барыбызга да күп итеп җылы су эчер, аннан йөгерергә мәҗбүр ит, хакыйкатьне күрерсең", - дигән. Күп итеп җимеш ашаучыларның барысы да йөгергәндә коскан, Локман Хәкимнең генә су чыккан. Хуҗа эшнең ни икәнен аңлаган. Локман Хәким зарланмаган, әләкләмәгән, хәтта акланмаган да, үзенең зирәклеге белән кыен хәлдән чыккан.

* * *

Локман Хәким Дауд (г-м) янына килгән. Дауд (г-м) тимерчелектә тимердән вак боҗралар ясау белән мәшгуль икән. Локман Хәким сәлам биреп килеп утырган, карап тора башлаган, нәрсә ясыйсың, дип сорамаган. Дауд (г-м) боҗраларны бер-берсенә тоташтыра башлаган, сугыш киеме - көбә күлмәк килеп чыккан. Сокланып: "Нинди нык күлмәк чыкты, хуҗасын дошман угыннан, кылычыннан саклар инде", - дигән.

Локман Хәким:

- Сабырлыгым аркасында сорау бирми дә эшеңнең нәтиҗәсен күрдем. Тәкъдиремне исемә төшердем. Тормышта Бер-берсенә бәйләнмәгән күпме вакыйгалар була. Кайберенә борчылабыз, бәргәләнәбез, сабыр итә белмибез. Безгә язган бездән беркая да китми, менә шушы күлмәк кебек - безнең өстә. Һәр эш Аллаһның тәкъдире белән. Бер-берсенә бәйләнгәч, тормыш була. Тормыш әнә шул боҗралар кебек ваклыклардан тора, вакланмасаң, бербөтен гүзәл кием кебек була. Вакланмыйча сабыр иткәннәр генә матур нәтиҗәсен күрә.

***

Локман Хәкимнең бер дусты булган, Локман Хәкимне шулкадәр хөрмәт иткән, ризыгын да иң элек аңа тәкъдим иткән. Бервакыт дустына кавын китергәннәр. Ул, кавынны кисеп, Локман Хәкимгә биргән, Локман Хәким бик тәмләп ашый башлаган. Аңа кызыгып дусты да ашый башлаган икән, кавын авызга алгысыз әче булган. Гаҗәпләнеп: "Ни өчен әче, дип зарланмадың?" - дигән. "Мин кавынга түгел, бирүче кулга игътибар иткән. Чын дус кулында әче әйбер дә татлы була, чын дус янында караңгылык та яктырып китә, авырлыклар да җиңеләя", - дигән Локман Хәким.

Ярату ул - үзең турында оныту. Чын дус дустының мәнфәгатен үз мәнфәгатьләреннән өстен куя, ул синең өчен тырыша, яхшы табиб кебек. Табиб та бит укол кадарга да мөмкин, әче дару бирергә дә, операция ясап, кайсыдыр җиреңне кисеп авырттырырга да мөмкин, ләкин ул аны синең өчен эшли. Җәләлетдин Руминың Локман Хәкимнең дусты кулыннан әче кавынны канәгать булып ашавы турындагы хикәясе дусларының туры сүзләрен дөрес кабул итә белергә өйрәтә, шул чак Локман Хәким кебек хикмәт иясе булырсың.

**Җәлил хәзрәт ФАЗЛЫЕВ**
**("Локман Хәким нәсыйхәтләре" китабыннан)**

# НИКАХ ӘДӘБЕ

***Сорау. Никахка кергән вакытта нинди әдәп һәм мөстәхәбәтләр бар? Бу вакытта нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?***

**Җавап.** "Әд-Дөррел-Мохтар" китабының никах бүлегендә болай диелә: "Никах турында игълан итү һәм аның алдыннан хөтбә уку, шулай ук никахны җомга көнне мәчеттә укыту – мөстәхәб (саваплы) гамәл булып исәпләнә. Никахны хак (акыллы) кеше гадел шаһитлар алдында үткәрергә тиеш. Хәнәфи мәзһәбе буенча шаһитлар ким дигәндә ике ир-ат яки бер ир-ат һәм ике хатын-кыздан торырга тиеш. Әгәр дә кияү кеше никах үткәрү өчен акчага мохтаҗ булса, ул аны бурычка алып тора ала. Шулай ук кияүгә чыгасы кызны никахка кадәр күрү дә хуплана. Кияүгә чыккан хатын-кызның өйләнүче ир-аттан яшьрәк булуы; нәсел затлылыгы, шөһрәтлелеге, байлыгы буенча түбәнрәк булуы мөстәхәб булып тора.

Кияүгә чыгучының өйләнүче ир-аттан әхлак сыйфатлары буенча югарырак, тәкъварак, чибәррәк булуы мөстәхәб булып исәпләнә".

Ибн Габидин үзенең "Хашия"сендә никах өчен акчаны бурычка алып тору мөмкинлеген шәрехләп, болай дип яза: "Чөнки бу бурычны кайтару өчен җаваплылыкны Аллаһ үз өстенә ала, әт-Тирмизи, ән-Нәсаи һәм ибн Маҗа тапшырган хәдистә болай диелә: "Аллаһ өч төрле кешеләргә ярдәм итәргә вәгъдә итте:

- ирегә өчен түләргә җыенган мөкатабка (үзенә ирек сатып алырга ниятләгән колга);

- өйләнеп, пакь булып калам (гөнаһлардан сакланам) дип ниятләгән кешегә;

- Аллаһ юлына чыккан кешегә".

Ибн Габидин: "Хатын-кыз ираттан яшькә кечерәк булырга тиеш",- дигән сүзләрне шәрехләп дәвам итә: "Бу - хатын-кыз тиз арада бәби таба алмаслык булмасын өчен кирәк (никахның төп максатларының берсе - нәсел калдыру)".

Нәселнең затлыгы турындагы сүзләргә аңлатма биреп, ул болай ди: "Бу - аның ата-бабалары хөрмәткә лаек һәм тәкъва кешеләр булуы өчен кирәк".

"Шөһрәтлелек һәм байлык" сүзләренә ул мондый аңлатма бирә: "Бу – аның хатыны аңа итагать итсен, аны хөрмәт итсен, кимсетмәсен өчен кирәк. Киресенчә булганда ул үзен иреннән өстенрәк хис итәчәк".

Ибн Хумам "Фәтхел-Кадыйр" китабында әт-Табарини, Әнәс ибн Малик тапшырган шундый хәдисне китерә: "Пәйгамбәр болай дигән: "Хатын-кызга аның билгеле кеше булганы өчен генә (дан-шөһрәте өчен) өйләнгән кешенең Аллаһ дан-шөһрәтсезлегеннән тыш бернәрсәсен дә арттырмас. Булачак хатынының байлыгы өчен өйләнгән кешенең Аллаһ фәкыйрьлектән тыш бернәрсәсен дә арттырмас. Ниндидер бер хатынның затлылыгы өчен өйләнгән кешенең Аллаһ түбәнлектән тыш бернәрсәсен дә арттырмас. Ә кем дә кем үзенең карашларын (чит хатыннардан) һәм җенес әгъзаларын (зинадан) читтә тоту һәм ныклы туганлык бәйләнешләре төзер өчен өйләнә икән, Аллаһ бу ир-атка бу хатын-кыз белән, ә бу хатын-кызга бу ир-ат белән яшәү өчен бәрәкәт бирер".

**Татарстан мөфтие**
**Камил хәзрәт**
**СӘМИГУЛЛИН**



# ИСТИХАРА

**"Кырыктагы мәхәббәт кар өстеннән яланаяк йөгертә", - дип бик белеп әйткәннәр икән шул борынгылар. Мин дә йөгердем ул кар өстеннән – аякларым өшегәнне сизмәдем, җәйнең челләсе тәнемне генә түгел, җанымны көйдерде – анысын да сизмәдем...**

Җилбәзәк хатын түгел мин. Бик яшьләй тол калганнан соң күз яшьләрем кипкәнне генә көттем дә, тормыш көтәргә керештем. Иремнең кабер туфрагы суынганчы ук капкамны шакучылар булды, димчеләр дә сүз каткалады. Мин "юк" дидем. Балаларым болай да ятим, инде аларны үги итиммени, дидем. Аллага шөкер, бүген "әни" дип өзелеп торган лачын кебек ике улым бар. Инде җитеш тормышта тыныч, кадерле картлыкны көтеп яшисе иде дә бит. Алда Аллаһының тагын бер сынавы көтеп торган икән – һич уйламаганда-көтмәгәндә гашыйк булдым.

Башта эштәгеләр сизеп алды. "Ни булды сиңа, кызый? Нинди шатлыгың бар?"- диләр. Аннары кием-салымның, прическаның үзгәргәнен сизеп алдылар да миңа дөрес диагноз куелды. Адәм көлкесенә калганчы, дип тизрәк ул эштән киттем. Башка эшкә урнаштым, бар да җайлашты кебек, яңа коллектив, эшнең җаен аласы бар, юк-бар нәрсә турында уйларга вакыт юк... Тик мин аны бер генә минутка да исемнән чыгара алмадым. Кешегә сөйли торган нәрсә түгел ичмаса. Сөйләсәм, синең яшьтә дөрес хәл түгел инде, бар, табибка күрен, диярләр иде, мөгаен. Бу халәтемнән ялгызым гына мәңге арына алмаячагымны аңлап, мәчеткә киттем. Сиксәнне узган бабай мине бер бүлмәгә алып кереп каршына утыртты да күзләремә туры карап: "Кызым, нинди борчуың бар?" – дип сорады. Оят булса да дөресен әйтергә туры килде. Ул бабай үз гомерендә күпне күргәндер инде, көлмәде, Аллаһы Тәгалә хәерлесен бирсен, дип, җиде азан әйтеп өшкерде.

Бабайның сулышы килештеме, мин тынычланып киткәндәй булдым. Әмма ул халәт озакка бармады... Шундый әрнүле-сагышлы көннәремнең берсендә, күптәнге танышым Лилияне очраттым. Аның: "Ни булды сиңа?" – диюе булды мин акырып елап җибәрдем. Ел буе эчемә җыеп килгән әрнүләрем язгы ташудай актарылып чыкты.

Лилия белән без мәчет каршындагы курсларда танышкан идек. Ул дингә ныклап ябышты, биш вакыт намазын калдырмый, гаиләсе дә чын мөселман гаиләсе. Минем генә намазлар укылганда укыла, укылмаганда юк. Хәзер шуның белән битәрли башлар инде, дигән идем, алай булмады үзе.

- Ә син истихара намазы укып карамадыңмы? – ди бу.

- Нинди истихара? Истихараны бит аны кайсы егетне сайларга белмәгән яшь кызлар укый...

- Укып кара әле, Аллаһы Тәгалә Үзе юлын күрсәтми калмас...

...Барысын да китап кушканча үтәдем: анда төнлә торып ике рәкәгать намаз укырга - беренче рәкәгатендә "Фатиха"дән соң "Кәфирун" сүрәсен, икенчесендә "Фатиха"дән соң "Ихлас" сүрәсен, сәлам биргәч, Истихара догасын укырга, диелгән. Намазны тәмамлап йөзне кыйблага каратып йокларга яттым. Төштә ак яки яшел төс күренсә, бу эш хәерле булачак. Ул минутларда мин өметемнең киселүен, иләс уйларымнан мәңгегә арынырга тели идем.

Дерт итеп уянып киттем дә торып утырдым, таң атмаган иде әле. Күргән төшем аермачык булып тагын бер кат күз алдымнан узды: башта экран кебек нәрсәдән чем кара тасма сызылып үтте, аннары аның өстендә җете яшел хәрефләр белән "Аллаһ" дигән язу чыкты, тагын ниндидер сүзләр тезелешеп китте, әмма минем гарәпчә белүем чамалы – аларын укый алмадым. Минә шундый төсле төш, әмма хикмәт төсләрдә түгел, ә "Аллаһ" дигән сүздәдер, дип уйлыйм. Ул мине рәхмәтеннән ташламас...

**А.МИҢНУЛЛИНА,**
**Казан**

## ИСТИХАРА ДОГАСЫ

Бу доганы Аллаһ Рәсүле (с.г.в) өйрәткән: "Аллаһуммә инни-стәхирукә би гыйльмикә, үә-стәкъ-дирукә би кодрәтикә, үә әсәлукә мин фадлыйк әл-газыйми фә иннәкә тәкъдиру үә лә акдиру үә тәгъләмү үә лә әгъләмү үә әнтә галләм үл-гуйүби. Аллаһуммә күнтә тәгъләмү әннә һәзә-ль-әмрә хәйрүн ли фи дини үә мәгаши үә гакыйбәти әмри гаҗилиһи үә әҗилиһи фә-кудурһү ли үә йәссирһү ли сөммә бәрик ли фиһи, үә ин күнтә тәгъләмү әннә һәзә-ль-әмрә шәррүн ли фи дини үә мәгаши үә гакыйбәти әмри гаҗили әмри үә әҗилиһи фәсрифһү ганни үә-срифни ганһү үә-кдур ли әл-хәйрә хәйсү әрдыйни биһи".

"Аллаһым! Синең белемең буенча хәерлене телим, кодрәтеңнән көч телим, синең бөек фазылыңны сорыйм. Син булдыра алучысың, мин булдыра алмам, син беләсең, мин белмәм. Син яшерелгәнне беләсең. Аллаһым! Әгәр син бу эшем минем динем, үткәнем, ахырым, бүгенем һәм киләчәгем өчен хәерле булачагын белсәң, моны миңа насыйп ит, җиңеләйт. Әгәр бу эш динем, үткәнем, ахырым, бүгенем һәм киләчәгем өчен начар булачак дисәң, моны миннән, мине дә моннан кире бор, яхшылык кайда булса, миңа аны насыйп ит. Мин риза булыйм" (Бохари: Дәгъвәт: 1/155).

Моннан соң теләгән әйтер.

## ЧИСТАЛЫКНЫҢ ҖИДЕ ТӨРЕ

**1. Кулның чисталыгы.** Ягъни үзеңнеке булмаган әйберләрне алмаска һәм байлыкның кырыктан бер өлешен мохтаҗларга бирергә, гади генә әйткәндә, сәдака биреп ярдәм итүдә саран булмау.

**2. Колакларның чисталыгы.** Ягъни гайбәт, фетнә һәм дошманлыкка чакыручы сүзләрне тыңламау.

**3. Күзләрнең чисталыгы.** Ягъни кешеләргә хөсетлек, бозыклык һәм вәсвәсә белән карамау.

**4. Авызның чисталыгы.** Ягъни буш сүздән, гайбәттән һәм чиктән тыш күп сөйләүдән тыелу. "Әйтер сүзең көмеш булса, әйтми калуың - алтын", ди халык.

**5. Тәннең, киемнең һәм яшәгән урынның чиста һәм пөхтә булуы.**

**6. Уй һәм фикернең чиста булуы.** Ягъни гөнаһлы фикерләргә юл куймау. Бигрәк тә кешеләр турында тиешсез начар уйламау.

**7. Йөрәкнең чиста булуы.** Ягъни көферлек, монафикълык, тәкәбберлек һәм хөсетлек чирләреннән пакь булу.

Хөрмәтле дустым! Пакьлек турында сүз барганда, Пәйгамбәребезнең (с.г.в.): "Чисталык – иманның яртысы", - дигән сүзләрен искә төшермәү һич мөмкин түгел. Югарыда язылган чисталык кагыйдәләрен үзеңдә булдыра алмаган кешене чын иманлы кеше дип әйтү авыр.

**Мәхмүт хәзрәт**
**ШӘРӘФЕТДИН**

# ҮЗЕ ЭШМӘКӘР, ҮЗЕ МУЛЛА

**Балык бистәсе районы Балтач (Юлсубино) авылына мулла итеп Фирдинанд билгеләнде. "Фирдинанд исемле мулла буламы!"- диде кемдер. "Менә күр дә тор, булдырачак ул!"- диде икенчесе. Каршылыклы фикерләрне еш ишетергә туры килде ул көннәрдә. Үз чиратында яшь мулла да: "Булдыра алырмынмы? Минем бит махсус белемем дә юк. Бу бит артык җаваплы эш. Безнең авылда минем кебек яшь кешенең мулла булып торганы да юк бит әле..."- дип борчылды, уйланды, икеләнде.**

Бер караганда, тормышыннан мең канәгать – тигез тормыш итүче әти-әнисе, район үзәгендә үсеп тә, авыл җирендә аның белән тормыш итәргә риза булган тормыш иптәше, буйга җиткән уллары, үз эше. Соңгысы авыл җирлегендә аеруча мөһим. Колхоз таралганнан соң, авылда бармак белән генә санарлык эш урыннары калды – авыл советында, мәктәптә, мәдәният йортында, почтада һәм вәссәлам. Билгеле, бик сайланып торырга мөмкинлек юк. Онытып җибәргәнмен лә, әле тагын ике вариант бар икән: я шабашка, я шешә. Ә Фирдинандның үз эше – авыл халкы өчен барлык кирәк-ярак белән тулы кибетләре бар аның. Авыл халкына районга, Казанга барып вакыт үткәрәсе, товар эзләп йөрисе юк, "менә шундый әйбер кирәк иде" дигән гозер белән аңа килсәң, син сораган ризыкны, төзелеш кирәк-ярагын икенче көнне үк капка төбенә кадәр китереп тә куя. Кайбер алыпсатарлар кебек, "мин булдырам, мин тегеләй иттем, болай иттем!" дип, шапырынмый-мактанмый, һәркем белән җайлап сөйләшә, һәр эшен җиренә җиткереп эшли.

Шундый эшләр белән кайнап йөргәндә авыл мәчетенә мулла булырга тәкъдим ясасыннар әле! Билгеле, ул диннән ерак кеше түгел, вакыты никадәр чамалы булса да, намазын, уразасын калдырмый, әмма шул ук вакытта сәүдә эше белән беррәттән мулла вазыйфаларын алып баруны да күз алдына китереп бетерә алмый. Беренчедән, мулла сүзе "укымышлы кеше, укытучы" дигәнне аңлата. Ул белгән авыл муллалары Рәшит абый Шәмсетдинов, Габделхәй абый Сөниев кебек абруйлы муллалардан соң, мәчеттә биш вакыт намаз, никах уку, балага исем кушу, кешене ахиргә озату кебек чараларда Аллаһы Тәгаләнең сүзләрен халыкка җиткерү - аеруча җаваплы гамәл. Икенчедән, инде җайга салынган, зур табыш китерә торган сәүдә эшен нишләтәсең...Шунысы кызык: кайбер авылларда мулла булырга теләк белдергән кешеләр шактый, ә Балтачта - киресенчә. Әлеге артык җаваплы эшкә әллә нинди дини, акыллы, абруйлы кешеләр дә алынырга җөрьәт итми. Ул гына да түгел, ни гаҗәп: авыл халкы нигәдер аны - Фирдинандны мулла итеп күрергә тели...

Ходай шулай язгандыр, күрәмсең, үзе эшмәкәр, үзе мулла Фирдинанд инде бер елга якын Балтач мәчетендә халыкны дингә өнди, остазы Габделхәй абый белән бергә мәчет тутырып яшьләр, картлар җыя. Моңа кадәр җомга намазына биш-алты кеше җыелса, хәзер ир-егетләрнең саны кырыктан артып китә. Намаз укыйлар, вәгазь тыңлыйлар, фикер алышалар. Күңелләрен сафландырып өйләренә таралалар. Ул гына да түгел, бөтен авыл халкы бергә зират чистарталар, Ураза, Корбан гаетләрендә мәчет янында бәйрәм табыны әзерлиләр, мәктәпкәчә яшьтәге балалар, мәктәп балалары белән әлеге бәйрәмнәрне зурлап, кичәләр оештыралар. Авыл халкы: "Әлхәмдүлилләһ, Габделхәй абыйга лаеклы алмаш килде, авылыбыз имамлы һәм иманлы булып яши", - дип сөенеп туя алмый.

Билгеле, хәзерге көндә Татарстанда һөнәри дини белемне тугыз мәдрәсәдә һәм бер университетта алырга мөмкинлек бар. Урта һөнәри дини белемне Кукмара, Мамадыш, Яр Чаллы, Буа, Урыссу, Әлмәт мәдрәсәләрендә, Казан шәһәрендәге "Мөхәммәдия", Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә, "Казан ислам көллияте"ндә алырга булса, югары белемле булырга теләгән абитуриентлар Казан ислам университетына юл тота. Һәр уку йортында да абруйлы, акыллы, дини һәм шул ук вакытта дөньяви белемгә ия булган остазлар белем бирә. Ләкин урта яки югары һөнәри диплом алу белән, студентлар Татарстанның ерак бер районына китеп имам булып эшләргә ашыкмый. Башкала яки башкала тирәсендәге районнар белән генә чикләнә алар. Чөнки диплом алу белән, аның өстенә берьюлы берничә вазыйфа һәм җаваплылык өелә. Төп вазыйфаларыннан тыш, мәчетнең коммуналь түләүләре, мәчет каршындагы курслар, мәчет бинасына ремонт ясау, түбән хезмәт хакы һәм башка йөз төрле мәшәкать белән күзгә күз очраша ул. Зур шәһәр эчендә яки шәһәргә якын районнарда әлеге проблемаларны бай спонсорлар хисабына хәл итәргә булса, авыл җирендә муллага гади авыл кешеләренә генә өметләнергә кала...

Белгәнебезчә, бүгенге көндә һөнәри дини белем бирүче уку йортлары студент өчен барлык мөмкинлекләр тудыра. Бөтенләй бушлай яки символик суммага гына ашау, яшәү, иң мөһиме – һөнәри белем алу мөмкинлеге ул. Диния нәзарәте дә грантлар ярдәмендә кайбер авылларны имамлы һәм иманлы итү өстендә эшли. Әмма, шуны ассызыклап үтәсем килә, җирле хакимият тарафыннан ярдәм булмаса, әлеге берьяклы гына тырышлык проблеманы хәл итми. Диния нәзарәте, дини белем бирүче уку йортлары, җирле хакимият бер максат куеп эшләгәндә генә авылларыбыз имамлы һәм иманлы булыр. Җирле хакимият абитуриентны максатчан рәвештә укырга җибәрсә, уку йортлары аны белемле, абруйлы имам итеп формалаштырса, җирле хакимият шул имамны каршы алып тиешле шартлар (хезмәт хакы, тору урыны, үзара аңлашып эшләү, уртак чаралар) тудырырга тиеш. Ә киләчәктә, билгеле инде, Диния нәзарәте аның хезмәтен күз уңында тотар.

Минем фикеремчә, Татарстанның ерак авылында шул авылда туып үскән, абруйлы нәселдән чыккан, акыллы, белемле, татар телен камил белгән, башкаларга үрнәк булырлык имам хезмәт итәргә тиеш. Нәкъ шундый мулланы гына авыл халкы үз итә, аңа иярә, аңа һәрдаим булыша. Минем язмамның героен - яшь имамны да авыл халкы үзе сайлады, ә өлкән яшьтәге тәҗрибәле аксакал Габделхәй абый аны әлеге дәрәҗәгә әзерләде. Хәзер инде булган белемне арттыру, һөнәри белем алуның яңа этабын башлап җибәрсә дә була.

Язмам ахырында, диплом алдым да имам булдым, түгел әле дигән фикерне тагын бер кат кабатлап үтәсем килә. Имам – һәрьяктан камиллеккә омтылучы, киң белемле шәхес, авыл халкы, балалар, ятимнәр, хатын-кызлар, ир-егетләр, аксакаллар, дөньяви хакимият белән уртак тел табып, ислам динен таратучы чын Кеше дә булырга тиеш.

**Нәзирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА (МОСТАФИНА),**
**Казан шәһәре**





# ХАҖИЛАР СҮЗ КУЕШТЫ

Районыбыз хаҗилары һәм хаҗияләре 27 нче февраль көнен календарьда кызыл белән билгеләп куйдылар, чөнки бу аларның берләшү, алга таба да ел саен очрашу көне булачак. Мамадыш шәһәре үзәк мәчетендә узган бу үзенчәлекле бәйрәм көне буена сузылды. Иртән анда мөнәҗәтләр яңгырады, казанда пылау пеште, халык Аллаһ йортына агылды.

Гади кешеләр түгел ул хаҗилар. Районыбызда аларның саны йөзгә якын. Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә Кәгъбә төзергә һәм халыкны хаҗга чакырырга әмер бирә: "Кешеләргә хаҗ турында белгерт һәм алар синең яныңа дөньяның төрле почмагыннан җәяү дә, дөягә утырып та киләчәкләр."("Хаҗ" сүрәсе, 27-32 нче аятьләр). Әлеге үзенчәлекле вазыйфаны үтәүчеләр гомер буе башкаларга бөтен яктан үрнәк булырга тиеш. Иң яхшы вәгазь – шәхси үрнәк. Бер-бер артлы сүз алган район мөхтәсибе Илһам хәзрәт Миннегалиев, Татарстан Республикасы Диния нәзарәте каршында оешкан "Хаҗ-2014" җитәкчелегенең Мамадыштагы вәкиле, үзәк мәчет имамы Наил хәзрәт Вахитов, тәэсирләрен яңарткан хаҗи Рәшит Таҗиев, хаҗия Рәсимә Гайфетдинова нәкъ шул турыда сүз алып бардылар. Мөхтәсибәттә җиде кешелек комиссия дә төзелде: аның составына хатын-кызлардан Рузалия Ибраһимова, Әлфия Сингатуллина, Рәсимә Гайфетдинова, ир-атлардан Рәшит Таҗиев, Нәсыйх Фазылрахманов, Нәкыйп Сәгыйтов, Хәмит Ясәвиев кертелде.

Кыска гына вакыт эчендә үзенең максатчанлыгы, бердәмлеге, матур эшләре белән танылып өлгергән мөслимәләрнең "Ак калфак" оешмасы җитәкчесе хаҗия Рузалия Ибраһимова сүз алды: "Хаҗ кылу – Аллаһ гыйбадәтен үтәргә ярдәм итүче изге сәфәр. Ул Аллаһы Тәгалә күрсәткән юлдан барырга, кылган гөнаһларыбыздан арынырга ярдәм итә. Хаҗга бару - зур хезмәт ул, чыгымнар һәм күркәм сабырлык сорый торган юл. Аллаһы Тәгалә кушкан гыйбадәтне кичектерергә һич тә ярамый. Хәтта мөмкинчелегебез булмаса да, һәрбер мөселман хаҗга бару нияте белән яшәргә һәм шул гамәлне чынга ашыруда Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорарга тиеш. Күңелләребездә дәрес ният булса, иншә Алла, изге теләкләр чынга ашар. Мөхәммәд Пәйгамбәрдән (с.г.в.): "Иң изге эш нинди була?" - дип сорыйлар. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Аллаһка ышану, изге юлда бару өчен көрәшү, һәм хаҗ кылу. Ул (ягъни хаҗ) башка эшләрдән күпкә артык", - дип җавап бирә.

Хаҗ кылу – кешенең матди ягын киметми. Киресенчә, изге сәфәр өчен тотылган чыгымнарны Аллаһы Тәгалә яңадан үзебезгә кайтарырга ярдәм итә.

Әгәр дә мөселман кешенең мөмкинлеге булып та, ул үз гомерендә хаҗ кылмаган икән, бу бурыч үлгәчтен дә аның өстендә кала. Ахирәттә аларның җаннары тыныч булсын өчен, үзләре өчен хаҗ кылып кайткан варислары, алар өчен дә изге сәфәргә барырга тиеш! Әгәр дә инде якыннарыгыз өстендә изге бурыч тормый икән, аңа хаҗ бүләген сорыйлар", - дип тәмамлады сүзен.

Инде шәһәрдәшләребез арасында үзенең тыңлаучыларын тапкан, яңа кешеләрне үзенә тарткан пәнҗешәмбе вәгазен бу юлы Алабуга җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Хәлим Шәмсетдинов (рәсемдә) сөйләде. Тәкъвалык турында вәгазь һәркемнең күңеленә хуш килде.

Мәҗлес шәһәребезнең "Диләрә" кафесында дәвам итте.

**Фирая МИНГАЛИЕВА,**
**Мамадыш шәһәре**

***Һәркем өчен дә үз туган ягы кадерледер. Кадерле түгел икән, димәк, ул кешенең бәхете дә тулы ук түгел.***
**Туфан Миңнуллин.**

**Тормыш сукмаклары мине быел да Татарстаныбызның урман-сулар, тарлавыклар-таулар кебек табигый байлыкларга мул гүзәл бер районына алып килде. Без килгән дәвалану үзәге хезмәткәрләре, күбесенчә татар кызлары, ачык йөз, тәмле сүз белән каршы алдылар, Аллаһының рәхмәте булсын аларга!**



# ГҮЗӘЛ ЯКНЫҢ БИЗӘКЛӘРЕ

Ике атна буе дәваланырга ниятләп килгән апамны матур итеп җиһазландырылган чиста, якты бүлмәдә калдырып, урамга атладым. Көн салкын түгел, салмак кына күбәләк кар ява. Районның үзәк мәйданы буйлап тезелеп киткән бер-берсенә һич охшаш булмаган матур биналар тирә-юньгә өстәмә ямь биреп торалар. Әнә банк бинасы янына рәт-рәт булып тезелеп киткән машиналар янында җиңелчә генә киенгән кешеләр кайнаша. Аннан ерак түгел генә, манарасындагы ярымайдан нурлар сибеп, кызыл кирпечтән төзелгән мәчет балкып утыра. Аннан ерак түгел чиркәү бинасы шәйләнә.

Берникадәр вакыт шулай тын гына басып тордым да, Казанга кире кайтырга кирәклеге исемә төшкәч, автобусның кайчан киләчәген белмәкче булып, читтәрәк торган бер хатынга мөрәҗәгать иттем. Ул миңа чатнап торган стройбат старшинасы тавышы белән, җим чүпләп йөргән чыпчыкларны да өркетерлек итеп: “Говори по-русски”, - дип җавап бирде. Вә ләкин мин бит чыпчык та, күгәрчен дә түгел, ә ата-бабаларыбыз мирас итеп калдырган туган җиребездә яшәп, туган телебездә сөйләшүче адәм баласы, шуларның бер варисымын... “Син инде, ханым, кунак булсаң – тыйнак бул. Тарас Шевченконы әнә 1850 нче елда патша хөкүмәте Казахстан җиренә сөргәч, ул иң беренче нәүбәттә казах телен өйрәнгән, аннан соң аларның гореф-гадәт һәм йолаларына төшенгән. Казах халкы белән дустанә яшәп, алар белән аралашып, аларның тарихын, тел һәм мәдәниятен барлап, ярдәмләшеп яшәгән. Ә кунакчыл һәм игелекле казах халкы аның хөрмәтенә үзләренең бер шәһәрен Шевченко дип атаган”,- дип сөйлисем бик килсә дә, минем телемнән башка сүзләр очып чыкты:

- Вы так похожи на третью жену Касыймхана, думал, вы его правнучка, поэтому был уверен, что язык наших предков знаете,- дидем.

Ул авызын япты. Янәшәсендәге 12-13 яшьләрдәге кыз баланың, минем җавапны аңлапмы, аңламыйчамы, шук кына елмаеп торуына күз салдым да мәйданның икенче ягына күчтем. Хуш исле чәчәкләргә күмелгән урман аланында сирәкмирәк күренгәләгән чүп үләннәре аның гүзәллеген киметә алмаган кебек “старшина”ның сүзләре дә бу якларның матурлыгын, монда гомер кичергән кешеләрнең ягымлылыгын киметә алмый иде. Уртача яшьләрдәге бер ир вә хатынның туган телебездә сөйләшеп торуларына игътибар итеп, алардан үземә кирәкле мәгълүматны алдым. Автобусның кузгалу вакыты өйлә намазына туры килү мине берникадәр борчуга салса да, үземнең мосафир икәнлегем искә төшкәч, тынычланып киттем; ярымайлары елмаеп, үзенә чакырып торган мәчеткә кереп, мәчет намазы укырга булдым. Матур коймалар белән әйләндереп алынган иркен ишегалдыннан үтеп, эчкә атладым. Кергәч күзгә чалынганы - беренче катның зур гына залында өстәл артына тезелешеп утырган ак яулыклы хатын-кызлар дәрес тыңлый иде. Яшь кенә мөгаллимә йомшак мәкам белән Коръән-Кәрим аятьләрен укып утыра. Аның баш кагуыннан минем мәчеткә керүемне хуп күргәнлеген аңлап, өс киемнәремне салдым да тәһарәтханәгә үттем. Андагы чисталык, кирәксә – салкын, кирәксә – җылы суның булуы күңелемне канатландырып җибәрде. Гыйбадәт залы җылы, якты, идәннәренә матур йомшак келәмнәр җәелгән. Намазым тәмамлангач та, тынычлык һәм рәхәтлек хисләреннән аерыла алмыйча, ошбу мәчетне төзегән, төзешкән һәм кулларыннан килгәнчә ярдәм иткән барлык инсаннарга багышлап дога кылып утырдым. Менә бит татарларыбыз бу гүзәл җирлектә динебез исламны, гореф-гадәтләребезне саклап, киләсе буыннарга мирас итеп калдырыр өчен ничек тырышып яталар. Район үзәгенең иң күркәм җирендә шушындый мәһабәт бина - Аллаһ йортын төзеп куйганнар...

***Син нишләп монда бөтен халык алдында гыйбадәт кыласың? Бар әнә мәчетеңә кереп укы, яисә өеңә кайтып кит!”- дип тә, башкача да тупаслык күрсәтмәде. Әлхәмдүлилләһ.***

Казанга кайтучы кешеләр байтак җыелды. Автобус кына никтер һаман күренми. Кышкы юл кышкы юл инде, расписаниедә күрсәтелгән вакытларга да үзгәрешләр керүе мөмкин. Менә өйлә намазының да вакыты керде. Көтмәгәндә минем башыма тагын бер фикер килеп, аңымны яктыртып җибәрде һәм мин тәвәккәлләдем. Яңа яуган ап-ак кар белән капланган мәйданның кешеләр йөрмәгән бер читенә барып бастым да намазга оедым... Сайлаган урыным, сукмак-юллардан читтәрәк булып, минем каршымнан кешеләр үтми иде. Талгын гына кар ява, салкын, саф һавада сулыш алуы рәхәт. Кемнәрдер мәйдан читенә куелган машиналарын кабызып, йомшак кына кузгалып китәләр. Боларның барысы да минем колагыма гына чалына, ә йөзем кыйбла ягында, күзләрем җемелдәп торган ак кар өстендә. Намаз укуы шундый җиңел. Коръән аятьләренең сүзләре үзеннән-үзе тел очына килеп тора. Мәйданга җыелган халык арасыннан бер генә кеше дә миңа: “Син нишләп монда бөтен халык алдында гыйбадәт кыласың? Бар әнә мәчетеңә кереп укы, яисә өеңә кайтып кит!”- дип тә, башкача да тупаслык күрсәтмәде. Әлхәмдүлилләһ.

Намазның соңында ошбу гүзәл җирләрдә яшәгән игелекле, киң күңелле һәм сабыр холыклы халыкка багышлап укыган догаларымны тәмамлап килгәндә, моторын гөрләтеп, карлы-бозлы юлда протекторларын шыгырдатып автобус та килеп туктады. Ашыкмыйча гына догамны тәмамлап, соңгылардан булып, автобус салонына күтәрелдем. Миңа калган урын уңайлы да, җылы да иде. Район үзәгенең урамнарын үтеп, Казаныбызга бара торган туры юлга чыккач, тәрәзә ягына ярым борылып, авыз эченнән генә юлда укый торган догаларымны кабатлый башладым. Бераз баргач, тел очымнан салмак кына тәгәрәп төшкән дога сүзләрендә ниндидер гадәти булмаган үзгәреш тоемлагандай булдым... Тукта! Бу бит кар өстендә укыган намазым вакытында кичергән хисләремнең рифмага салынуы түгелме? Укыган догаларымны тиешенчә багышлап, битемне сыпырдым да зиһенемә үрмәләгән рифмалар белән “аңлаша” башладым. Алар камиллектән ерак торса да, мин кичергән хисләргә бик тә тәңгәл иде...

Тирә-юньнең пакьлегендә
Намазлыгым аклыгында
Хошуг белән намаз укыйм
Раббым разыйлыгына.

Энҗе карлар йомшак кына
Керфегемә кагылганда
Кулым баглап намаз укыйм
Раббым разыйлыгына.

Намазлыгым – ап-ак карда.
Беленерлек эзем калса,
Булыр идем мин чиксез шат,
Раббым кабуллардан кылса...

Рөкүгъ илә сәҗдә кылам,
Кар өстендә эзләр кала;
Мосафирның намазлары
Кабул булыр, иншә Аллаһ!

Намазларым кабул булса –
Кабул булыр теләкләрем,
Күңелемдә мәңге калыр
Гүзәл якның бизәкләре...

**Мәгариф РАЯНОВ,**
**Кама Тамагы - Казан**

## ХӘДИСЛӘР

Диннең афәте – өч: бозык фәкыйһ (шәригать белгече), рәхимсез имам (дәүләт башлыгы, кабилә рәисе) һәм надан мөҗтәһид (дин эшендә тырышлык күрсәтүче).

Гыйлем афәте – өч: аны оныту, я гыйлем әһеле булмаган кешеләргә шул хакта сөйләп, аны югалту.

Бәндәләр ничек утырса- мин дә шулай утырырмын, ничек ашаса – мин дә шулай ашармын.

Монафикълык галәмәте – өч: сөйләсә – ялганлый, биргән вәгъдәсен боза һәм аманәткә хыянәт итә.

Чакырылсагыз, чакырган җиргә барыгыз.

Иң элек үзеңнән башла – сәдаканы башта үзеңә бир, үзеңнән артканын – гаиләңә, гаиләңнән артканын якыннарыңа, якыннарыңнан артканын шул рәвешле башкаларга бир.

Сезгә сөенеч бирәм, үзегездән соңгыларны сез дә сөендерегез, кем: “Юк Аллаһтан башка бүтән тәңре”, - дип гуаһлык бирә һәм шуңа тугры кала, шул җәннәткә керә.

* * *

“Бәхет” дигән ул сүзнең мәгънәсен
Аңлый бугай һәркем үзенчә...
Олыгайгач кына ясыйбыз шул
Узган гомерләргә нәтиҗә.

Кемдер бәхет санап, коеныпйөри,
Тән кыздыра ерак Канарда;
Кемдер һәр ел бара Мисырына
Эссе комда ятып аунарга.

Кайсылары җыя хәрам маллар,
Уздырам дип барлык кешедән;
Җыйган байлыгына горурланып,
Сәлам бирми үтә кешегә.

Без дөньяга бәхет өчен туган,
Язмыш сыный безне үзенчә;
Бу дөньяга минем үз карашым,
Бәхетне дә аңлыйм үземчә.

Бәхет бит ул үз илеңдә яшәү
Гаиләң булса бердәм, бербөтен;
Бу дөньяның матурлыгын күрсәң,
Киләчәккә булса өметең.

Бәхет дигәненең иң олысы
Гомер юлын парлап үтүдә;
Хәзер кайтыр, диеп чәең куеп,
Бер-береңне сагынып көтүдә.

Эшләп тапкан малың бәрәкәтле,
Хәләл ризыгың булса ашарга,
Яшәешнең ямен-тәмен тойсаң,
Өметең булса алда яшәргә,

Аллаһының ярлыкавын сорап
Башың куя алсаң сәҗдәгә,
Балаларың синең эздән килсә -
Нинди бәхет кирәк бәндәгә?

**Мәрьям СИТДЫЙКОВА,**
**Әл-Мәрҗани мәчете мәхәлләсе**

# Россия мөселманнарының җиде ядкаре

**Russia Beyond The Headlines сайты (“Российская газета”ның халыкара проекты) Россия мөселманнары мөбарәк санаган урыннарны – төрбәләр, шифалы чишмәләр, каберлекләр, тарихый һәйкәлләр исемлеген игълан итте. Татарстанда һәм Башкортстанда андый урыннар бик күп, Төньяк Кавказда да байтак мөселман ядкарьләре саклана.**


## Ингушетиядәге Борга-Каш төрбәсе



Бу төрбәнең кайчан һәм ни өчен төзелгәнлеге турында тарихчылар бер фикергә дә килә алмый. Кайбер галимнәр аны, берәрсенең сөйгәне каберенә төзелгәндер, дип саный. Бу урында гарәп шәехе җирләнгән, диючеләр дә бар. Риваятькә караганда, үлеме якынлашканын сизгән шәех, үзенең дөясенә атланып, далага чыккан. Дөясен җибәргән дә ул туктаган урында төрбә төзергә булган, имеш. Хәзерге заман галимнәре бу төрбә Үзбәк ханның идарәчесе – җирле хакимнекеге дигән фикердә.

600 елдан артык әлеге төрбә олы мирас булып санала. Әлегә чаклы бинада гарәп язулары сакланган. Кайбер чыганакларга караганда, анда берничә агач табут ята.


## Кораешләр ныгытмасы - Кала



Кала ныгытмасы диңгез өстеннән 1000 метр биеклектә урнашкан. Бу - Кавказда ислам таралганнан соң төзелгән беренче ныгытма. Ул VII гасырда кораеш кабиләсе токымы тарафыннан төзелгән. Аны икенче төрле Мачу-Пикчу дип тә атыйлар. Ныгытма текә тау битендәге таш лабиринтны хәтерләтә.

Биредә IX гасырда Россиянең иң борынгы мәчете төзелгән. Анда борынгы төрбә һәм музей да бар.


## Дагстандагы Түтибикә төрбәсе



Дагстанның Дербент шәһәрендә Төньяк Кавказ мөселманнары кадерләп саклый торган ике урын бар: Түтибикә төрбәсе һәм Кырхляр. Төрбә 1787-1788 нче елларда Дербент ханы тарафыннан хатыны һәм идарәдәше Түтибикә өчен төзелгән. Риваятьләргә караганда, Түтибикә бик зирәк хатын булган, аның аркасында Дербент тугыз айлык камалыштан җиңеп чыккан.

Аннан ерак түгел урнашкан Кырхлярда мөселман миссионерлары җирләнгән. Риваятьләргә караганда, биредә Төньяк Кавказда исламны тарату юлында һәлак булган 40 гарәп гаскәрие ята.

## Чечнядагы Кунт-Хаҗи Кишиев зираты



Чечняда изге саналган 59 каберлек – зират бар. Аның иң мәшһүре Хаҗи авылында урнашкан. XIX гасырда бу авылда чечен миссионеры, суфый шәех Кунт-Хаҗи Кишиев туган. Аның туган нигезе яныннан гына шифалы чишмә агып ята. Теләгән кешеләр Кишиевның әнисе каберен дә зиярәт кыла ала, ул якындагы Эртин тавында урнашкан.

## Татарстандагы Бөек Болгар шәһәрчеге



Татарстан башкаласы Казаннан 140 чакрым ераклыкта Идел ярында борынгы Болгар шәһәрчеге бар. Болгар - урта гасырның иң бөек шәһәрләренең берсе.

Бүгенге Болгар - XIII-XIV гасыр архитектура һәйкәлләрен: Җәмигъ мәчет, Көнчыгыш һәм Төньяк төрбә, Хан төрбәсе, Кече Манара, Карапулат, Акпулат, Хан мунчасы һәм башка архитектура объектларын эченә алган зур шәһәрчек.

Болгар тыюлыгының Көньяк капкасында Ак мәчет төзелде. Аны төзүдә бөтендөнья ислам архитектурасының иң яхшы үрнәкләре файдаланылган. Архитектура комплексы мәчет бинасыннан тыш үз эченә мөфти резиденциясен һәм мәдрәсәне ала.

## Башкортстандагы Хөсәенбәк төрбәсе



Уфадан ерак түгел XII-XIV гасырларда төзелгән ике төрбә бар. Аның берсе Акзиратта урнашкан. Риваять буенча, төрбә хәзерге Башкортстан территориясендәге беренче имам Хаҗи Хөсәенбәк өчен бөек Тамерлан әмере буенча төзелгән, имеш. Төрбәдән ерак түгел Тамерланның гаскәр башлыкларына куелган гарәп язулы кабер ташлары саклана.

Шушы урыннан 10 чакрымда тагын бер борынгы төрбә – Турухан каберлеге бар. Кайбер тарихчылар фикере буенча, Турухан да Чыңгызхан нәселеннән, Хөсәенбәк кебек үк укымышлы мөселман хакиме булган.

## Әүлия чишмәсе



Башкортстандагы Әүлия чишмәсе Көньяк Уралның Авыштавыннан бәреп чыга. Чишмә дәвалау үзлегенә ия. Ул нибары утыз көн генә ага, шул утыз көн эчендә ел саен үз янына меңләгән кешене җыя. Әйтүләренә караганда, аның суы бөердәге ташларны кудырып чыгара, сулыш юллары, ашказаны авыруларын дәвалый. Әүлия чишмәсе суы 15 нче майдан соң гына дәвалау үзлегенә ия була икән.

Авыштауга менү ике этаптан тора: аның беренче этабы Әүлия чишмәсенә җитү булса, икенче этап – тау башына менү. Тау башында өч кабер бар, риваятьләргә караганда, XIII гасырда анда җирле халык тарафыннан үтерелгән Ош шәһәренең өч миссионеры җирләнгән. Тәүбә кылганнан соң халык анда шәех Мөхәммәд Рамазан әл-Ушны һәм аның иптәшләрен җирләгәннәр. Шуннан соң тау битеннән чишмә бәреп чыккан, имеш.

# “ИТЕГЕЗ ХӘЛӘЛМЕ?”

**Бик еш кына безнең кайсы милләттән булуыбыз автоматик рәвештә теге яки бу дингә тиңләнә. Әгәр православие дине вәкиле дисәләр, димәк, рус кешесе күз алдында тотыла, әгәр бу кеше татар дисәләр, аны мөселман дип саныйлар. Бүгенге көннең стереотиплары (бернинди фикерләүсез иярелә торган, үзгәрмәүчән гомум кабул ителгән үрнәге) шундый. Гәрчә, чынлыкта, бу алай ук түгел. Руслар арасында да мөселманнар бар, татарлар арасында да христиан динендә булган керәшеннәр бар. Шуңа да карамастан, бу стереотиплар иҗтимагый фикерне билгели. Нәкъ менә шундый фикер хәләл продукция кулланучыларны ялгыш юлга этәрә дә инде. Моның белән үз товарларын күбрәк сатарга теләгән сатучылар файдалана. Нәтиҗәдә бу нәрсәгә китерә соң?**



Соңгы елларда “Хәләл” тамгасы белән җитештерелгән продукциягә ихтыяҗ зур. Шуңа да чынлыкта хәләл булмаган продукцияне хәләл итеп сату өчен төрле алдауларга барырга тырышалар. Сатып алучыларны үз товарыңа җәлеп итүнең иң җайлы ысулы - аны “мөселманча” яки “татар милләтенә хас булганча” дигән ярлык (этикетка) белән чыгару. Әмма андый ярлыклы товарларның хәләл продукциягә бернинди дә катнашы юк.

Базарга баргач: “Хәләл казылык бармы?” - дип сорасаң, күп вакытта уңай җавап ишетергә туры килә. Кайчак аның этикеткасына хәтта “хәләл” дип тә язылмаган продукцияне тәкъдим итәләр. Күпчелек очракта мондый товарларның ярлыгында “мөселманча” дип язылган, яки кайсы да булса мәчет рәсеме төшерелгән, яисә аның тышлык кәгазе гарәп каллиграфиясе стилендә язылган була. Андый язулар әлеге продукциянең хәләл икәнлеген түгел, бары тик составында дуңгыз итенең булмавын гына аңлатырга мөмкин.

Казандагы районнарның берсенә атна саен бер машина килеп, халыкка “100% хәләл” дип “авыл ите” сата. Итнең хәләлме-юкмы икәнлеген ачыкларга теләсәң, бу сатучының: “Бу хәләл ит, чөнки ул татар авылларының берсеннән”, - дигән сүзләрен ишетәсең. Баксаң, бу “эшмәкәрнең” үз товарының хәләллеген раслый торган документлары гына түгел, санитаргигиена таләпләренең үтәлеше, аңа сәүдә итәргә рөхсәт ителү буенча бирелә торган белешмәләре дә юк. Кешеләр сатучының сүзләренә ышана, “яңа гына суелган” һәм иң мөһиме - “хәләл” итне тизрәк алып калырга дип чиратка тезелә.

Товар җитештерүчеләр еш кына аның хәләл булуын раслаучы бернинди документлары булмаса да, үз продукцияләрен хәләл дип игълан итә.

Кызганыч ки, шәригать кануннары буенча продукция җитештерү һәм сатуны җайга салу өчен Россиядә хәләл продукциягә дәүләт стандартлары (ГОСТ) юк. Шул сәбәпле, хәләллек күрсәткеченә бердәнбер гарантия булып иркеле рәвештә РОССТАНДАРТта теркәлү узган “Хәләл” сертификациясе алу системасы тора. Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең “Хәләл” стандарты буенча комитет продукциянең хәләллеген билгеләгәндә нәкъ менә шул системаны куллана да инде.

Шуңа күрә, сатып алучыларга зур үтенечебез бар: хәләл ит продукциясен бары тик тикшерелгән һәм моның белән сату итәр өчен тиешле документлары булган сату нокталарыннан гына алыгыз. Сездән шулай ук хәләл продукцияне җитештерү һәм сату тәртипләрен бозу һәм алдау очраклары буенча Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең “Хәләл” комитетына мөрәҗәгать итүегезне үтенәбез.

Безнең адресыбыз: 420021 Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 3 нче йорт.

Телефон: +7 (843) 238-33-71 (факс), +7 (843) 238-65-11, +7 (843) 210-30-80, +7 (843) 292-20-08, +79600332030.

Электрон почта адресы: info@halalrt.com.

Интернеттагы сайтыбыз: www.halalrt.com.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең “Хәләл” комитеты шулай ук ризык сатып алганда түбәндәгеләргә игътибар итәргә киңәш бирә:

1. Төрү материалында “хәләл” билгесе һәм җаваплы оешманың исеме булырга тиеш.

2. Хәләл дип аталучы ризыкның составын җентекләп тикшерегез.

3. Составында терлек мае, желатин, алкоголь булган продуктларны кулланмагыз.

4. Әгәр азык-төлекнең берәр ингредиенты (берәр катлаулы матдәнең, кушылманың состав өлеше) шик уята икән, аның турында интернет челтәреннән мәгълүмат эзләгез яки http://halalrt.com/questions сайтының “Хәләл турындагы сорауларыгыз” бүлегенә кереп, ”Хәләл” комитет вәкилләреннән белешегез.

5. “Хәрам” яки “шикле” дип табылган “Е” кодлы ингредиентлар таблицасын үзегездә булдырыгыз.

6. Хәләл ит ризыклары хәләл булмаган белән бергә сакланырга тиеш түгел.

7. Терлек кулдан яки механик юл белән чалынганмы – шуңа игътибар итегез. Моның өчен һичьюгы эре җитештерү предприятиеләрендә бу эшнең кайсы ысул белән башкарылуын белү мөһим.

# “ХИЗБҮТ-ТӘХРИР”ГӘ НИ КИРӘК?

**Узган ел Россия мөселманнары өчен “Хизбүт-тәхрир” партиясенең актив эшчәнлеге кебек күңелсез күренеш белән истә калды. 2013 нче елның көзеннән илебезнең күпчелек төбәкләрендә җомга намазларыннан соң мәчетләрдә бу оешманың 5-6 вәкиле, илдә мөселманнарның хокуклары бозыла дип, тавыш куптара, башкаларны низагка тарта башлады. Коръәни-Кәримне, хиҗапны рөхсәт итмиләр, тыялар, исламны законнан тыш дип игълан итәләр, дигән хәбәр таратып, мөселманнарны дәүләткә каршы котырта башладылар.**

Дөреслектә исә бу оешма әгъзаларын бер генә нәрсә – аларның оешмалары Россиядә тыелган булуы борчый. Дөрес булмаган фикерләрен таратырга рөхсәт итмәү аларның үз-үзләрен тотышларында чагылыш таба. Күпчелек мөселманнарның аларның өндәүләренә җитди карамаулары, аларга ышанмаулары ачуларын чыгара. Бу алар Россия мәчетләрендә үткәргән акцияләр вакытында, лозунглары ялган булуын аңлап, мөселманнарның аларны тыңламауларында да ачык күренде.

Мөгаен, “Хизбүт-тәхрир”гә кергән кешеләр “мөселманнарның хокукларын бозу” дигәндә бу оешма тарафдарларын тыелган оешма эшчәнлегендә катнашкан өчен тоткарлауларны күз алдында тоталардыр. Максатларына ирешер өчен алар мөселманнарны кысрыклау турындагы лозунглар артына яшеренәләр. Россия мөселманнарының күпчелеге “Хизбүт-тәхрир” тарафдарларын мөселманнарны берләштерергә җыенмаган, ислам дине кыйммәтләре турында оныткан, ялгыш юлдан киткән сектантлар дип саный, әмма “хизбүт-тәхрир”челәр генә моны аңламый. Аларның максаты башка – мөселман өммәтендә фетнә чыгару.

“Хизбүт-тәхрир”челәрнең иң зур ялгышы – мөселманнар исламның Мәккә чорында яшиләр дип фикер йөртүләре. Төгәлрәк әйткәндә, алар Россиядә яшәүче мөселманнарга Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) заманында ислам дине урнашуның башлангыч чорына кайтырга тәкъдим итәләр. Ләкин мөселманнарның күпчелеге “хизбүт-тәхрир”челәрнең мондый “вакыт машинасы”на ышанмыйлар, чөнки бу ислам диненең камил һәм тәмамланган булуы турындагы догмага каршы килә. Коръәни-Кәримдә: “Менә бүген динегезне төзеп бетереп, тулы кылдым, бирәсе нигъмәтләремне дә ислам дине белән бергә биреп бетердем сезгә һәм риза булып ислам динен сезгә ихтыяр кылдым”, - диелә (“Маидә” сүрәсе, 3 нче аять). Аллаһы Тәгалә кешеләргә Үзе ислам диненең Пәйгамбәребез (с.г.в.) белән камил килеш килүен әйтә, һәм аның урнашуының бер этабын гына сайлау һәм беренче чорының нормаларын безнең заманга күчерү – зур ялгыш.

“Хизбүт-тәхрир”челәрнең Мәккә чоры турындагы сүзләре мәчет һәм мәдрәсәләр төземәс өчен аклану гына. Аларга мөселманнарны яшерен төстә үз оешмаларына тартуны бу чор өчен норма буларак аңлату өчен кирәк. Ачык дини бәхәстә катнашырга теләмәүне җиңел аңлатып була – мәчет һәм мәдрәсәләрдә кешеләрне үзләренә ияртергә өндәсәләр, белеме булган мөселманнар алар тәгълиматының ялгыш булуын күрә алыр иде.

“Хизбүт-тәхрир”челәр алар белән килешмәүче дин эшлекләрен һәм галимнәрне тәнкыйтьлиләр, ләкин бөтен кешене “Хизбүт-тәхрир-әл исламия”гә нигез салучы Тәхутдин ән-Нәбхани фикеренә кушылырга өндиләр. Ә бит ислам диненең мең еллык тарихы классик сәхабәләр белән аралашкан, күп санлы китаплар язган, безгә динебезне аңлаткан классик галимнәрдән алып, традицион ислам диненең хәзерге заманга туры килүен дәлилле алган соңгы гасырларның атаклы мөселман галимнәре плеядасын бирде.

Әһле Сөннәт вәл җәмәгать галимнәренең күпчелеге ән-Нәбханине галим буларак танымыйлар, аның фикерләрендәге хаталарны күрсәтәләр. Суфыйчылык һәм сәләфиләр кебек капма-каршы агымнар галимнәренең күпчелеге дә “Хизбүт-тәхрир” партиясе карашларын кире кага. Ләкин чынлыкта кайбер сәләфиләр сәяси максатларына ирешер өчен бу секта белән берләшергә дә әзер.

Мөселман галимнәре бертавыштан “Хизбүт-тәхрир” идеологиясен тәнкыйтьләүгә карамастан, аның тарафдарларының сукырларча укытучылары артыннан баруы бу оешманың секта булуына бер дәлил. Бу оешманың төп эш ысулы – спекуляция һәм сафсата. Бу оешма хәлифәтне торгызу темасында спекуляцияләре белән билгеле һәм үзенең барлык гамәлләрен бары тик шул максатка ирешергә теләве белән аңлата. Кешеләрне утопиягә ышанырга мәҗбүр итү – теләсә нинди сектаның иң киң кулланылган ысулы.

**Сөләйман АЙДИНОВ**

## ҖӨМӘДИӘЛӘҮВӘЛ

Бу айның борынгы исеме – ханин. Аның тарихы турында китапларда болай дип язылган: "Гарәпләр үз гомерләрендә беренче мәртәбә сукы көннәрне суның бозга әйләнгәнен күргәч бик гаҗәпләнгәннәр. Бу вакыйга нәкъ көз башына туры килү сәбәпле аның исемен дә "җөмәдиәл әүвәл", ягъни "көз башы" дип атарга булалар (Ибн Кәсир, "Тәүбә" сурәсенең 36 нчы аяте тәфсире).

3 нче җөмәдиәләүвәлдә Гомәр (р.г.) иман китереп, ислам динен кабул итә (ул вакытта барлыгы 40 мөселман була) һәм шул көнне Кәгъбәтуллаһ потлардан тазартылып, анда өйлә намазы укыла.

8 нче җөмәдиәләүвәлдә Гали (р.г.) дөньяга килә.

Шулай ук 8 е көнне хәзрәти Хәмзә белән хәзрәти Габбас, Аллаһка иман китереп, мөселман булалар.

13 нче җөмәдиәләүвәл - сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) яраткан кызы хәзрәти Фатыйманың вафат булган көне.



## СҮЗ ЙӨРТҮЧЕНЕ АКЫЛГА УТЫРТКАН

Бер кеше Хәсән Басри хәзрәтләренең янына килеп: "Фәлән синең турыда начар сүзләр әйтте", - дигән.

- Кайчан?
- Бүген.
- Кайда?
- Өендә.
- Аның өендә нишләдең?
- Кунакка бардым.
- Кунакта нәрсә ашадың?

Ул сигез төрле ризык исемен саный. Шунда Хәсән Басри:

- Ул адәмнең сигез төрле ризыгын эченә сыйдыргансың, ә бер сүз сыймадымы? Чык бу урыннан, - дигән һәм гайбәтчене куып чыгарган.

## ЯСМЫК

Коръәндә искә алынган ризыкларның тагын берсе – ясмык (чечевица). Ясмык кулинариядә киң кулланыла. Бу продукт крахмалга, үсемлек аксымына, фосфор һәм витаминнарга бай. 100 грамм ясмыкта 57 грамм углевод, 24 грамм аксым, 25-30 мг натрий, 64 мг кальций, 0-5 мг B1 витамины бар. Ясмыкның атеросклероз, йөрәк авырулары, диабет, ракка каршы файдасын күрәләр. Аның составындагы матдәләр күз күрүен яхшыртуда, интеллектны үстерүдә, мускулларны һәм нервны ныгытуда да ярдәм итә.

Кузаклы культуралар арасында ясмык иң тиз эшкәртелә торганы. Бала имезүче хатын-кызларга, симерүдән, эч кибүдән, баш мие авыруларыннан интегүчеләргә ясмык ризыклары ашарга киңәш итәләр.

Аннан аш, ботка, төрле салатлар, хәтта камыр ризыклары да әзерләргә мөмкин. Шунысын да әйтергә кирәк: аксымга бай, бик тәмле һәм файдалы булуына карамастан, аның бәясе ит ризыкларыныкына караганда шактый түбән.



## УКЫРГА БЕЗГӘ КИЛЕГЕЗ

| Уку йортының тулы исеме | Лицензия номеры | Юнәлеш исеме | Квалификация (хәзерлек дәрәҗәсе) (лицензия буенча!) | Укыту формасы, уку сроклары | Кабул итү имтиханнары | Кирәкле документлар | Кабул итү комиссиясенең телефон номеры; электрон почтасы; интернеттагы (рәсми) сайты; уку йорты адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Мөселман дини оешмасы – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең "Казан ислам колледжы" урта һөнәри дини белем бирү учреждениесе | № 29 (2011 нче елның 3 нче мартыннан) | Дин әһелләре һәм мөселман дине белән бәйле дини оешмаларга хезмәткәрләр хәзерләү | Имам-хатыйб, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллиме | Уку йортына йөреп уку, 3 ел | Рус теле; әңгәмә | Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3x4 үлчәмдә фоторәсем (8 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе | +7 (843) 293-81-51 (факс белән); haziev-bobo@mail.ru; http://kikrt.com/; 420021 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зәйни Солтан урамы, 6/15 йорт. |
| Мөселман дини оешмасы – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Кукмара мәдрәсәсе | № 343255 (2010 нчы елның 29 нчы апреленнән) | Ислам фәннәре һәм тәрбия Гарәп теле | Имам-хатыйб, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллиме | Уку йортына йөреп уку-читтән торып уку, 4 ел | Юк (бары әңгәмә генә) | Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; анкета; 3x4 үлчәмдә фоторәсем (2 данә); белем алу турында соңгы документ копиясе | +7 (84364) 2-66-75; +7 (84364) 2-61-27; +79033402544; rishat.kuramshin@mail.ru; интернетта рәсми сайт юк; 422110 Татарстан Республикасы, Кукмара посёлогы, Мичурин урамы, 6 нчы йорт. |
| Мөселман дини оешмасы – Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Ризаэддин Фәхреддин исемендәге Әлмәт ислам мәдрәсәсе урта һөнәри белем бирү учреждениесе | № 3740 (2012 нче елның 27 нче мартыннан) | Дин әһелләре һәм мөселман дине белән бәйле дини оешмаларга хезмәткәрләр хәзерләү | Имам-хатыйб, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллиме | Уку йортына йөреп уку, 3 ел Читтән торып уку, 4 ел | Август аенда абитуриентлар өчен оештырылган лагерьда уку мәҗбүри; әңгәмә; Коръән уку; Ислам нигезләрен белү | Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3x4 үлчәмдә фоторәсем (4 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе | +7 (8553) 45-69-45 (факс белән); medresealmet@yandex.ru; kalimulla80@mail.ru; интернетта рәсми сайт юк; 423450 Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Шиһабетдин Мәрҗани урамы, 82 «А» йорт +79518924925 (тәрбияче) Хатын-кызлар бүлеге (Волгоградская урамы, 24 нче йорт) +7 (8553) 43-74-88 |
| Мөселман дини оешмасы – Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең "Ак мәчет" Чаллы мәдрәсәсе урта һөнәри дини белем бирү учреждениесе | Серия номеры 002439 № 3889 (2012 нче елның 17 нче апреленнән) | Дин әһелләре һәм мөселман дине белән бәйле дини оешмаларга хезмәткәрләр хәзерләү | Имам-хатыйб, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллиме | Уку йортына йөреп уку, 3 ел Кичке уку, 3 ел Читтән торып уку, 4 ел | Әңгәмә | Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3x4 үлчәмдә фоторәсем (4 данә); белем алу турында документ (уку йортына йөреп укучылар өчен – оригиналы, кичке һәм читтән торып укучыларга – күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе | +7 (8552) 38-67-02; imam@akmechet.ru; www.akmechet.ru; 423810, Татарстан Республикасы, Чаллы шәһәре, Энтузиастлар бульвары, 12 нче йорт (Яңа шәһәр, 2/12). |
| Мөселман дини оешмасы – Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Буа мәдрәсәсе урта һөнәри дини белем бирү учреждениесе | № 4935 (2013 нче елның 11 нче апреленнән) | Дин әһелләре һәм мөселман дине белән бәйле дини оешмаларга хезмәткәрләр хәзерләү | Имам-хатыйб, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллиме | Уку йортына йөреп уку, 3 ел Кичке уку, 3 ел | Әңгәмә | Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3x4 үлчәмдә фоторәсем (8 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе | +7 (84374) 3-70-71; islam-buinsk@mail.ru; интернетта рәсми сайт юк; 422430 Татарстан Республикасы, Буа шәһәре, К.Либкнехт урамы, 79 нчы йорт. |
| Мөселман дини оешмасы – Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Мамадыш мәдрәсәсе урта һөнәри дини белем бирү учреждениесе | № 4136 (2012 нче елның 29 нчы маеннан) | Дин әһелләре һәм мөселман дине белән бәйле дини оешмаларга хезмәткәрләр хәзерләү | Имам-хатыйб, ислам нигезләре һәм гарәп теле мөгаллиме | Уку йортына йөреп уку, 3 ел Уку йортына йөреп уку-читтән торып уку, 4 ел Читтән торып уку, 4 ел | Тарих; рус теле | Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3x4 үлчәмдә фоторәсем (8 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе | +7 (885563) 3-19-17; mamadysh-medrese@mail.ru; интернетта рәсми сайт юк; 422190 Татарстан, Мамадыш шәһәре, М.Җәлил урамы, 8/28 йорт. |
| Мөселман дини оешмасы – Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең "Фәнис" Урыссу мәдрәсәсе | № 743 (2010 нчы елның 11 нче ноябреннән) | Ислам фәннәре гарәп теле, тәрбия һәм дин әһеле | Имам-хатыйб һәм мөгаллим (гарәп теле укытучысы) – яшь егетләр өчен Тәрбияче һәм мөгаллимә (гарәп теле укытучысы) – кызлар өчен | Уку йортына йөреп уку, 3 ел Читтән торып уку, 4 ел | Әңгәмә | Паспорт копиясе; кабул итү турында гариза; 3x4 үлчәмдә фоторәсем (8 данә); белем алу турында документ (оригиналы яки нотариуста раслатылган күчермәсе); анкета; 086/У формасы буенча медицина белешмәсе ИНН, СНИЛС, медицина полисы күчермәләре | +7 (85593) 2-69-07; maratmardanshin@rambler.ru; www.medrese-fanis.ru; 423950 Татарстан Республикасы, Урыссу посёлогы, Пушкин урамы, 24 нче йорт. |

ДИН вә Мәгыйшәт

**Гамәлгә куючы: Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27) .*
**Нәшир: "Хузур" нәшрият йорты** *(420111 Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в).*

**Март саны, № 3 (224)**

**Баш мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ
**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Фанис Мотыйгуллин
**Корректор:** Айгөл КРОХИНА
Газета логотибы **хәттат** Рамил НАСЫЙБУЛЛОВ тарафыннан эшләнде

**Редакция советы:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;***
*"Хузур" нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;***
*Татарстан мөфтие урынбасары **Нияз САБИРОВ;***
*Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;***
*Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе **Габдулла ӘДһӘМОВ.***

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).
Заказ № 09609
**Тираж: 10 мең данә**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя – 6 сум.
График буенча бу санга **24 нче март көнне 18.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде. **Кул куелды: 18.00 сәгатьтә.**

**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
**Электрон адрес: niyaz-kazan@yandex.ru**
**Телефон:** +7 (843) 267-29-67.

**Язылу индексы: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин.**